1.Ахатов, Г.Х. Лексика татарского языка : учеб. пособие для студ. пед. вузов .— Казань : Тат. кн. изд-во, 1995 .— 91,[2]с. — (На тат. яз.) – 35 экз

2. Закиев, М.З. Татарский синтаксис : учеб. для вузов .— Казань : Магариф, 2005 .— 398с. – 14

3.Сафиуллина, Ф.С. Современный татарский литературный язык : учеб. для высш. и сред. учеб. заведений / Ф.С.Сафиуллина, М.З.Закиев .— Казань : Магариф, 1994 .— 318с. — (На тат. яз.) – 10 экз.

**6. Фонд оценочных средств для проведения промежуточной аттестации обучающихся по дисциплине (модулю)**

**6.1. Перечень компетенций с указанием этапов их формирования и описание показателей и критериев оценивания компетенций на различных этапах их формирования, описание шкал оценивания.**

| Планируемые результаты освоения образовательной программы | Этап | Показатели и критерии оценивания результатов обучения | | | | Вид оценочного средства |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | 2. | 3. | | | | |
| | | неуд. | удовл. | хорошо | отлично | |
| готовностью сознавать социальную значимость своей будущей профессии, обладать мотивацией к осуществлению профессиональной деятельности (ОПК-1). | 1этап: Знания Обучающийся должен знать: теоретический материал по фонетике, орфографии, орфоэпии, графике, лексикографии, фразеологии, грамматике современного татарского языка и истории формирования и развития жанров в татарской литературе | Фрагментарные знания теоретического материала по фонетике, орфографии, орфоэпии, графике, лексикографии, фразеологии, грамматике современного татарского языка, по истории формирования и развития жанров в татарской литературе | Общие, но не структурированные знания теоретического материала по фонетике, орфографии, орфоэпии, графике, лексикографии, фразеологии, грамматике современного татарского языка, по истории формирования и развития жанров в татарской литературе | Сформированные, но содержащие отдельные пробелы в знаниях теоретического материала по фонетике, орфографии, орфоэпии, графике, лексикографии, фразеологии, грамматике современного татарского языка, по истории формирования и развития жанров в татарской литературе | Сформированные систематические знания теоретического материала по по фонетике, орфографии, орфоэпии, графике, лексикографии, фразеологии, грамматике современного татарского языка, по истории формирования и развития жанров в татарской литературе | Устный опрос |
| | 2 этап: Умения: анализировать языковые единицы разных уровней языка; анализировать художественные произведения татарских писателей, поэтов и драматургов | Не умеет анализировать языковые единицы разных уровней языка; анализировать художественные произведения татарских писателей, поэтов и драматургов | В целом успешное, но не систематически осуществляемое умение анализировать языковые единицы разных уровней языка; анализировать художественные произведения татарских писате- | В целом успешное, но содержащее отдельные пробелы в умениях анализировать языковые единицы разных уровней языка; анализировать художественные произведения татарских писателей и поэтов, драматургов | Сформированное умение анализировать языковые единицы разных уровней языка; анализировать художественные произведения татарских писателей, поэтов и драматургов | Письменная работа |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | лей, поэтов, драматургов | | | |
| | 3 этап: Владения (навыки / опыт деятельности) нормами литературного языка в области фонетики, орфографии, орфоэпии, графики, фразеологии, лексикографии, грамматики современного татарского языка и литературоведческими терминами, навыками анализа художественных произведений | Фрагментарное владение нормами литературного языка в области фонетики, орфографии, орфоэпии, фразеологии, лексикографии, грамматики современного татарского языка и литературоведческими терминами, навыками анализа художественных произведений; выполнено менее 50% тестовых заданий | Слабое владение нормами литературного языка в области фонетики, орфографии, орфоэпии, фразеологии, лексикографии, грамматики современного татарского языка и литературоведческими терминами, навыками анализа художественных произведений; выполнено от 50 до 70% тестовых заданий | В целом успешное, но содержащее отдельные пробелы в применении норм литературного языка в области фонетики, орфографии, орфоэпии, фразеологии, лексикографии, грамматики современного татарского языка и литературоведческими терминами, навыками анализа художественных произведений; выполнено от 70 до 80% тестовых заданий | Успешное и систематическое применение норм литературного языка в области фонетики, орфографии, орфоэпии, фразеологии, лексикографии, грамматики современного татарского языка и литературоведческими терминами, навыками анализа художественных произведений; выполнено от 80 до 100% заданий | тесты |
| Готовностью использовать систематизированные теоретические и практические знания для постановки и решения исследовательских задач в области образования (ПК-11) | Обучающийся должен знать: лингвистические понятия и термины, основные источники по современному татарскому языку и литературе . | Обучающийся не знает лингвистические понятия и термины, основные источники по современному татарскому языку и литературе . | Обучающийся слабо знает лингвистические понятия и термины, основные источники по современному татарскому языку и литературе . | Обучающийся хорошо знает лингвистические понятия и термины, основные источники по современному татарскому языку и литературе . | Обучающийся отлично знает лингвистические понятия и термины, основные источники по современному татарскому языку и литературе | Устный опрос |
| | Обучающийся должен уметь: владеть навыками грамотного оперирования лингвистическими и литературоведческими терминами | Обучающийся не владеет навыками грамотного оперирования лингвистическими и литературоведческими терминами | Обучающийся слабо владеет навыками грамотного оперирования лингвистическими и литературоведческими терминами | Обучающийся хорошо владеет навыками грамотного оперирования лингвистическими и литературоведческими терминами | Обучающийся отлично владеет навыками грамотного оперирования лингвистическими и литературоведческими терминами | Контрольная работа |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Обучающийся должен владеть: навыками выполнения научно-исследовательских работ по татарскому языку и литературе | Обучающийся не владеет навыками выполнения научно-исследовательских работ по татарскому языку и литературе | Обучающийся слабо владеет навыками выполнения научно-исследовательских работ по татарскому языку и литературе | Обучающийся хорошо владеет навыками выполнения научно-исследовательских работ по татарскому языку и литературе | Обучающийся отлично владеет навыками выполнения научно-исследовательских работ по татарскому языку и литературе | рефераты |

**6.2. Типовые контрольные задания или иные материалы, необходимые для оценки знаний, умений, навыков и (или) опыта деятельности, характеризующих этапы формирования компетенций в процессе освоения образовательной программы**

**Перечень вопросов к устному опросу**

**Перечень вопросов для оценки уровня сформированности компетенции ОПК-1 на этапе «Знания»**

**1 курс 1 семестр**

1. Фонетиканың өйрәнү объекты. Фонетика терминының тел гыйлемендә киң һәм тар мәгънәләрдә куллану мәсьәләсе.
2. Өйрәнү максатына карап фонетиканың төрләре: хосусый, гомуми, тасвирлама, тарихи, эксперименталь, чагыштырма, синтаксик.
3. Татар фонетикасының өйрәнелү тарихы.
4. “Татар теле фонетикасы” курсы, аның эчтәлеге, бурычлары, өйрәнү объекты.
7. Авазларны акустик яктан өйрәнү.
8. Сузык һәм тартык авазлар, төп аермалары.
9. Сузык фонемаларның саны һәм составы. Алынма сузыклар.
10. Татар телендә сузык авазлар, аларны төркемләү.
11. Тартык авазларны төркемләү.
12. Дифтонглар турында төшенчә.
13. Иҗек. Иҗек калыплары. Иҗек төрләре.
14. Синтагма турында төшенчә. Пауза, аның сөйләмдәге роле.
15. Сүз басымы, аның татар телендә роле.
16. Интонация, аның сөйләмдәге роле.
17. Авазларның позицион үзгәрешләре: протеза, эпентеза, редукция.
18. Авазларның комбинатор үзгәрешләре: аккомодация, ассимиляция, диссимиляция, аларның төрләре.
19. Татар телендә сингармонизм законы, аның төрләре. Рәт гармониясенә буйсынмаган очраклар.
20. Ирен гармониясе.
21. Авазлар чиратлашуы.

**1 курс 2 семестр**

1. Орфоэпия турында төшенчә. Аның бурычлары һәм әһәмияте.
2. Әдәби әйтелешне бозып сөйләү, аның сәбәпләре.
3. Әдәби әйтелеш төрләре: тулы стиль һәм сөйләшү стиле.
4. Орфоэпик нормаларның төп принциплары.
5. Сузыкларның дөрес әйтелеше.
6. Тартыкларның дөрес әйтелеше.
7. Рус теленнән һәм башка теллардән кергән сүзләрнең әйтелеше.
8. График турында төшенчә.
9. Хәзерге татар алфавиты. Аваз һәм хәреф мөнәсәбәте.
10. Орфография турында төшенчә, аның әһәмияте.
11. Татар орфографиясенең төп принциплары. Фонетик, морфологик, график, тарихи-традицион.
12. Хәрефләрнең дөрес язылышы.

13. Сүзләр һәм кушымчаларның дөрес язылышы.
14. Сүзләрне аерып, кушып, сызыкча аша язу.
15. Сүзләрне юлдан юлга күчерү.
16. Сүзләрне кыскарту.
17. Татар орфографиясенең кыен очраклары.

**2 курс 3 семестр**

1. Фразеология, аның предметы.
2. Фразеологик берәмлекләрнең төп билгеләре һәм татар телендә аларның төрләре.
3. Фразеологик берәмлекләрнең барлыкка килү юллары.
4. Фразеологик берәмлекләрнең матур әдәбиятта һәм публицистикада стилистик кулланылышы.
5. Лексикография турында төшенчә, аның төп бурычлары.
6. Сүзлекләрнең төрләре, аларның фәнни-практик әһәмияте.
7. Татар теленең сүзлекләре.
8. Татар лексикографиясенең кыскача тарихы.
9. Татарларда филологик сүзлекләр.
10. Татар тел белемендә аңлатмалы сүзлекләр төзү тарихы.
11. Русча-татарча сүзлекләр төзү тарихы.
12. Совет чорында төзелгән сүзлекләр.
13. Терминнар сүзлекләре.
14. Орфографик, фразеологик сүзлекләр.
15. Диалектологик һ.б. сүзлекләр.

**2 курс 4 семестр**

1. Татар морфологиясенең кыскача тарихы.
2. Морфология турында төшенчә. Морфологиянең тел белеме тармаклары белән бәйләнеше.
3. Татар телендә сүзләрне төркемләү принциплары.
4. Мөстәкыйль мәгънәле, бәйләгеч һәм модаль сүзләрнең сөйләм оештырудагы роле.
5. Сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәте. Сүзләрнең бер сүз төркеменнән икенче төркемгә күчү мәсьәләсе.
6. Субстантивация күренеше.
7. Адъективизация күренеше.
8. Адвербиализация күренеше.
9. Исемнщрнең бәйлекләргә күчүе
10. Сыйфатларның бәйлекләргә күчүе.
11. Фигыльләрнең бәйлекләргә күчүе.
12. Рәвешләрнең бәйлекләргә күчүе.
13. Конверсия юлы белән кисәкчә ясалышы.
14. Конверсия юлы белән ымлыкларның ясалышы.

**3курс 5 семестр**

1. Интонация турында төшенчә.
2. Фраза басымы. Пауза. Логик басым. Тойгы басымы. Сөйләм көе.
3. Интонациянең төрләре. Хәбәр итү интонациясе.

4. Санау интонациясе. Каршылык интонациясе. Күтәрү интонациясе.
5. Сүзләрнең үзара бәйләнеш төрләре һәм аларның сөйләмне оештырудагы роле.
6. Хәбәрлекле мөнәсәбәт .
7. Хәбәрлекле мөнәсәбәтне белдерүче чаралар.
8. Тәгәлләүле мөнәсәбәт һәм аны белдерүче чаралар.
9. Аныклаулы мөнәсәбәт һәм аны белдерүче чаралар.
10. Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар.

**4 курс 7 семестр**

1. Сүзтезмә турында гомуми мәгълүмат. Сүзтезмәләрне өйрәнү тарихы.
2. Сүзтезмәләрнең төрләре. Өйрәнү бурычларыннан чыгып сүзтезмәләрне төркемләү.
3. Фигыль сүзтезмәләр. Исемле фигыль сүзтезмәләр.
4. Санлы фигыль сүзтезмәләр. Төп үзенчәлекләре.
5. Рәвешле һәм сыйфатлы фигыль сүзтезмәләр.
6. Фигыльле фигыль сүзтезмәләр.
7. Исем сүзтезмәләр. Исемле исем сүзтезмәләр.
8. Сыйфатлы һәм рәвешле исем сүзтезмәләр.
9. Санлы исем сүзтезмәләр.
10. Фигыльле исем сүзтезмәләр.
11. Хәбәрлек сүзле исем сүзтезмәләр.
12. Сыйфат сүзтезмәләр. Исемле сыйфат сүзтезмәләр.
13. Рәвешле сыйфат сүзтезмәләр.
14. Фигыльле сыйфат сүзтезмәләр.
15. Алмашлык сүзтезмәләр.
16. Сан сүзтезмәләр.
17. Рәвеш сүзтезмәләр.
18. Хәбәрлек сүз сүзтезмәләр

**4 курс 8 семестр**

1. Пунктуация турында гомуми мәгълүмат.
2. Тыныш билгеләрен төркемләү.
3. Җөмлә төзелеше, мәгънәсе һәм тыныш билгеләре.
4. Нокталың куелу урыннары.
5. Сорау һәм өндәү билгеләренең куелу урыннары.
6. Күп нокталарның куелу урыннары.
7. Өтернең куелу урыннары.
8. Нокталы өтернең куелу урыннары.
9. Ике ноктаның куелу урыннары.
10. Сызыкның куелу урыннары.
11. Җәяләрнең куелу урыннары.
12. Куштырнакларның куелу урыннары.

**5курс 9 семестр**

1. Текст турында төшенчә.

2. Текстны өйрәнү тарихы.
3. Микротекст һәм макротекст.
4. Текстның бөтенлеге.
5. Текстның башламы.
6. Текстның структурасы.
7. Текстның композициясе.
8. Чит сөйләмле текст.
9. Кыек сөйләм.
10. Туры сөйләм.

**5 курс 10 семестр**

1. Стилистика фәне, аның өйрәнү предметы, бурычлары.
2. Стилистика фәненең телнең башка тармаклары белән бәйләнеше.
3. Стилистиканың сөйләм һәм язу эшчәнлеген үстерүдәге әһәмияте.
4. Стилистик нормалар һәм вариативлык.
5. Әдәби тел һәм әдәби телгә кермәгән сүзләрнең (диалект, жаргон, гади сөйләм лексикасы) үзенчәлекләре.
6. Язма һәм сөйләм теле нормалары.
7. Стилистикада синонимия күренеше.
8. Авазларның стилистик кулланылышы.
9. Әйтелеш стильләре.
10. Сузык һәм тартык авазларның әйтелеше.
11. Аллитерация, ассонанс күренешләре.

**6 курс 11 семестр**

1. Рус һәм татар телендә фонетика бүлеге.
2. Рус һәм татар телендә сузык авазлар системасы.
3. Рус һәм татар телендә тартык авазлар системасы.
4. Рус һәм татар телендә басым.
5. Рус һәм татар теленең алфавиты. Кайбер орфографик кагыйдәләр.
6. Рус һәм татар телендә сүз төзелеше.
7. Рус һәм татар телендә сүз ясалыш юллары һәм ысуллары.
8. Рус һәм татар телендә сүз төркемнәре. Исем сүз төркеме. Исемдә род (җенес) категориясе.
9. Исемнәрдә сан категориясе. Тартым категориясе.
10. Рус һәм татар телендә исемнәрдә килеш категориясе.

**Перечень вопросов для оценки уровня сформированности компетенции ОПК-1 на этапе «Умения»**

**Письменная работа**

**1 курс 1 семестр**

***Бирем. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә фонетик анализ ясарга.***

1. Илкәй белән бергә **сагынам**
   Яшьли сөйгән яркәйне. (Х.ж.)

2. Әллә яңгыр ява,
Әллә **яшьләр** тама,
Юлларыннан киткән кошларның. (Д.Булгакова)

3. **Кайгылы** күңлем талында
Яңгырады кылларың. (Н.Исәнбәт)

4. **Уятма,**йокласын, син, ана,
Айларны, елларнысанап бар. (Р.Әхмәтҗанов)

5. Уфа **юкәләре** безнең хакта да әле
Яфрак яра-яра сөйләрләр. (Н.Нәҗми)

6. Хуш, **авылым**, сау бул,
Сәламнәр көт,
Таң җилләре искәндә. (Х.Фатхуллин)

7. Узар **гомерләр** аккан су кебек,
Гомер бер генә, сөю мәңгелек. (Зөлфәт)

8. Сез искә алыгыз яшьли сөйгән
Беренче **яраткан** ярларны. (Ә.Рәшитов)

9. Тормыш юллары катлаулы,
Бер **ялгызың** юл үтмә. (Ә.Атнабаев)

10. Алтын көз **көнендә,**
Басу киңлегендә
Утырттык без япь-яшь имәннәр. (Г. Рамазанов)

11. Әйләнә **яфраклар**, әйләнә, әйләнә,
Офыкта инде көз шәйләнә. (Т.Низами)

**12.** Зур **тормышлар** кочкан чаклар бер вакыт кына,
Алма кебек матур чаклар бер вакыт кына. (З. Нагаева)

13. Мине **юллар**, юллар чакыра...
Китәсең, дип авыр сулама. (Н.Нәҗми)

14. Диңгезнең дә була төрле чагы,
Бер **давыллап** ала, бер тына. (Ш.Галиев)

15. Синең белән еллар кичергәндә
**Бәхет** юлдаш минем юлымда. (Н.Нәҗми)

16. Нинди кыллар чиртте, **бәгърем,**
Ул матур яшь кулларың? (Н.Исәнбәт)

17. Ак чәчәкләр кебек кар ява,
Хәтерләтеп ямьле май кичен. (Г.Идрисов)

18. Кызыл-кызыл **бөрлегән** лә,
Күл буена тезелгән, шул. (Х.җ.)

19. Кайчак күзләреңнән көчләр алып,
**Бөеклеккә** табан ашам мин. (Һ.Такташ)

20. **Шиңгән** чәчкәләр кабат терелер,
Кайту хәбәре синнән килгәч тә.. (Р.Мөслимов)

**1курс 2 семестр**

**Текст 1**

**Бирем 1.** ***Текстны транскрипциядә бирегез. Әйтелеш һәм язылыштагы аермаларны күрсәтегез.***

Әллә шул чакта, әллә чак кына соңрак, егетнең колагына каяндыр җыр ишетелде. Татарча җыр!.. Егет, өне катып, тынып калды. Нәрсә ишетә ул, кемне ишетә? Йа Хода, аның Таһирәсе җырлый түгелме соң? Шул ич, шул, Таһирә тавышы! Кайда ул?.. Егет, үзен белештермичә, яткан җиреннән кинәт бер омтылып куйды. Шунда ук аның күз аллары караңгыланып китте, башы хәлсезләнеп, мендәр читенә авып төште. Шәфкать туташы, куркынып, тизрәк аның кулын алды, пульсын капшады. Әмма егет һушыннан язмады, дөресрәге, һичнәрсәне, һичкемне сизмәс булса да, җырны ишетүдән туктамады. Яңадан бөтен дөньясы эссе томанга йотылса да, җыр... җыр калды.

Ә бу җыр чынлыкта бар иде, ул янәшәдәге эшелонның бер вагоныннан килә иде. Әгәр теплушка белән кызыл вагонның ишекләре бер–берсенә капма–каршы туры килгән булсалар, ишек яңагына сөялеп, кулларын шинель җиңнәренә тыгып җырлап торучы кыз, ихтимал, үзе дә күренгән булыр иде. Ләкин теплушканың аз гына ачык ишегеннән ут яктысы кыздан читкәрәк, кызыл стенага тар гына сары юл булып төшкән иде. (Ә. Еникидән)

## Текст 2

**Бирем 1.** ***Текстны транскрипциядә бирегез. Әйтелеш һәм язылыштагы аермаларны күрсәтегез.***

Авылның исеме аның уртасыннан челтерәп аккан чишмә исеменнән алынган. Көмешлесу чишмәсе Уба тавыннан агып чыга да, кояш нурларында чагылган энҗе бөртекләредәй саф суыннан елгачык хасил итә. Суы шулкадәр чиста аның, төбендәге вак ташлар, кечкенә балык, маймычлар да көзгедәгедәй күренеп торалар. Чишмә агып төшеп Кытай җирендәге Зайсан күленнән башланган олпат Иртешкә коя. 4248 чакрымга сузылган бу олы себер елгасының юлында никадәр күп мондый чишмәләр! Ил төкерсә – күл булыр, ди халык. Әнә шундый меңләгән чишмә-елгачыклар аны туендыра, яшәү көче бирә. Көмешлесу да Чал Иртешнең уйнак нәбәрәсе кебек: кояш нурларында күзләрне чагылдырып, яшь киленнәрнең чулпы тавышларын хәтерләтеп, чылтырап көлә, назланып ага, уйнаклап боргалана да, иркә песи баласыдай, олатасының култык астына кереп, тынычлана.

**2 курс 3 семестр**

**Бирем 1. Тексттан фразеологик берәмлекләрне табыгыз, мәгънәләрен аңлатыгыз. Рус телендә аларга туры килгән фразеологик берәмлекләрне табыгыз.**

1.Байның талканы коры иде. 2. Хәер, кешеләр бөтен җирдә дә Сәлмән карт кебек ике яклы пычак түгелләрдер, алай булмаска тиешләр. 3. Ул инде бервакытта да балавыз сыгып маташмаска ант иткән иде. 4. Иген чәчәм дисәң – аты юк, чәчмәсәң – ачтан аяк сузмак кирәк. 5. Хәзер килеп аның турында кайбер кеше, бигрәк тә аның тәлинкәсен ялап йөрүче ялагайлар: “Ул – көтүчедән баеган кеше, аның чыбыркысы белән чикмәне әле дә булса чормада саклана, имеш” – дигән буш сүзләр таратып йөрсәләр дә, үзенең ничек баегынын Сәлмән бүтәннәргә караганда яхшырак белә. 6. Бу – осталык, авыз белән кош тоту, судан коры чыга белү. 7. Тик шулай да үзенең авызы колакка җиткән иде. 8. Алар, төрлесе төрле якка чабып, таралып беттеләр, муллага каршы тел катучы булмады. 9. Зәйтүнә Сәфәргалинең шуклыгын, тел бистәсе булуын белсә дә, аннан мондый хыянәтне көтмәгән иде.

**Бирем 2. Тексттан фразеологик берәмлекләрне табыгыз, мәгънәләрен аңлатыгыз. Рус телендә аларга туры килгән фразеологик берәмлекләрне табыгыз.**

**1.**Җитмәсә, аның Җаектан ишетелгән тавышына колак сала башладылар. 2. Казан чакыра, ләкин Уральск чабудан тоткан. 3. Ерак та түгел кебек үзе, кояш нурларын чагылдырып ялтырый торган

Идел өстеннән яланаяк йөгерсәң, күз ачып йомганчы барып та җитәрсең шикелле. 4. Шәкерт абыең ни җитте кеше түгел бугай. 5. Ямьсез тынлык озакка сузыла башлагач, Тукай телгә килде. 6. Трай тибеп йөргәнче, критик кына буласың бар. 7. Танылган әдипләр генә түгел, авызыннан сөт кипмәгән малайлар да монда политика, әдәбият, сәнгать диңгезендә колачлап йөзәләр. 8. Пушкин белән Лермонтовны тәнкыйтьләргә көче җиткән Белинский, Писаревларның әсәрләрен су кбек эчәләр. 9. Габдулланың күңел почмагында шыксыз бер тойгы баш калкытырга азапланса да, хәзергә әле күңел күге аяз, күкрәк кояшы якты иде. 10.

**2 курс 4 семестр**

**1.Тексттан конверсия ысулы белән ясалган сүзләргә мисаллар китерегез**
**2.Тулы морфологик анализ ясагыз (2-3 сүзгә).**

Миңа Түбән Камада, шул як авылларында, Казанның үзендә Сара ханым белән берничә әдәби-музыкаль кичәдә, төрле очрашуларда катнашырга туры килде. Шул кичәләрдә минем өчен аның тагын бер күркәм сыйфаты, аның популярлыгының тагын бер “сере” ачылды.

– Дусларым, туганнарым! Мин сезне бик-бик яратып, якын итеп килдем! – дип башлый ул сүзен. Шулкадәр ихлас күңелдән, җаннарны эретердәй итеп шундый үткәреп әйтә, бу сүзләр залда да шундый ук дуслык, туганлык тойгысы кабызып җибәрә дә тамашачы дәррәү килеп кул чаба башлый. Һәм шул сулыштан Сара ханым тамаша залын бөтенләе белән үз кулына алып, аның кәефе белән үзе идарә итә башлый. Ул, көлдерә-көлдерә, үзенең ничек артист булып китүен сөйли, пианинода әле кичә генә язган яңа көен уйный, ул да түгел, әгәр кирәк икән, үзе уйнап, үзе җырлап та җибәрә. Ничә тапкырлар сокланып утырганым бар: сәхнә Сара ханымның стихиясе, аның тормышының иң җанлы, күңелендә канәгатьлелек тудыра торган иң нәтиҗәле өлеше иде. Шактый өлкән яшьтәге бу ханым сәхнәгә килеп чыгу белән кинәт яшәреп, йөзе яктырып – матурланып китә, тавышы торган саен көчәя, батырая бара, ул халыкка җан азыгы бирә алуы, аны рухландыруы белән, үзенең аңа кирәклеге белән илһамланып, шуннан җан рәхәте табып сөйли иде. Сара ханым сәхнәдә чагында тамаша залында бер генә дә битараф, ваемсыз чырайны күрми идең.

Минем бу хакта да уйланганым бар. Сара ханымның әнә шулай килеп чыгуы белән бөтен тамаша залын “яулап алуы”нда һичшиксез аның артистлык талантының да зур өлеше бар иде. Ләкин ул гына да түгел. Моны Сара ханымның халыкка булган тирән ихтирамының сәхнәдә гәүдәләнеше дип тә карарага кирәктер. Шәһәрдә булсын, авылда булсын, композитор үзенең чыгышларының һәркайсына, кыен, фәнни имтихан бирергә җыенгандай, бөтен дөньясын онытып, барлык тырышлыгын куеп әзерләнә торган иде.

Сара ханым Садыйкова музыкабызга бай мирас калдырды. Аның бик күп әсәре татар музыкасының беркайчан да искерми, кадерен югалтмый торган алтын фондына керер. Алай гына түгел, Сара ханым үзенең композиторлык иҗаты белән татар халкының бик борынгы заманнардан бирле үк бай рухи тормыш белән яшәп килүче музыкаль халык икәнлеген тагын бер мәртәбә раслады.

“Мәдәни җомга” газетасыннан.

**Текст**

Оренбурның татар җәмәгатьчелеге дөньясында зур вакыйга булып узды. 21-22 сентябрьдә биредә “Вакыт” гәзитенең 100 еллык юбилеен билгеләп үттеләр. Хәер, өлкәдәге милләттәшләребез өчен икеләтә бәйрәм: басманың кече туганы булган “Яңа вакыт”ка – 15 яшь. 1918 елда ябылган гәзит. 90 нчы еллар башында яңа сулыш ала. Хәзер аның 3 меңгә якын әбүнәчесе бар. 165 мең татар яшәгән Оренбур өлкәсе өчен, бу, әлбәттә, күп түгел. Моны гәзит хезмәткәрләре үзләре дә таный. Сәбәбен яшь буын арасында телне белүчеләр аз булу белән аңлаталар.

Узган гасыр башында Оренбур татар мәдәниятенең бер учагы булган. Гыйлем, мәгърифәт, милли сәнгатьне үстерү юнәлешендә актив төбәкләрнең берсендә ул чорда йөзләгән мәчет-мәдрәсәләр эшләп килә, беренче татар театр труппасы оеша. Тәүге татар басмаларын нәшер итү буенча өлкәнең лидерлар рәтендә булуы гаҗәп түгел. Алтын приискалары хуҗалары – бертуган Рәмиевләр акчасына чыгарылган “Вакыт” гәзите алар арасында аерым урын тота. Редакция бинасы өчен Оренбурда 40 мең сумга зур йорт сатып алалар. Заманча типография техникасы белән җиһазлыйлар. Финанс ягыннан кытлык кичермәсәләр дә, рәсми

рөхсәт алу авыргарак туры килә. Инде, ниһаять, хакимияттәгеләрнең хәер-фатыйхасы алынгач, гәзитнең баш исеме өчен клише ясау берничә  ай вакытны ала. Аны Санкт-Петербургта  гына ясаганнар. Оренбур һәм күрше-тирә шәһәрләрдә мондый остаханәләр булмый. Татар матбугатының чишмә башында торучыларга нинди авырлыкларга тарырга туры килүен без хәзер күз алдына да китерә алмыйбыз.

Гарәп графикасы белән язылган “Вакыт”ны бүген бик сирәкләр генә укый ала. Әмма ул чорда зур форматлы, 4 битле басма иң күп тиражлы матбугат чараларының берсе булган. Күренекле мәгърифәтче Фатих Кәриминең мөхәррир булып торуы да күп нәрсә турында сөйли. Ачылганда атнасына 2-3 тапкыр чыккан басма соңрак көн саен нәшер ителә башлый. 20 нче гасырның иң популяр гәзите белән күренекле татар зыялылары: Галимҗан Ибраһимов, Риза Фәхретдинов, Зәки Вәлидиләр дә хезмәттәшлек итә. Тема төрлелеге шактый зур булып, “Вакыт” иске ысул белән укытучы, ягъни кадими белем йортларын реформалауга да үз битләрендә зур игътибар биргән.

“Мәдәни җомга” газетасыннан

**Текст**

Безнең һәвәскәр “Сәйяр” ансамбле студентлар фестиваленнән соң бик тиз танылып китте. Безне мактап газеталарга яздылар, төрле клуб, сарайларга чакыра башладылар. Ә җәй көне, каникулга чыгу белән, өлкә комсомол комитеты гастрольгә җибәрде. Дүрт җәйдә без байтак район әйләндек.

Быел безгә Чаллы-Минзәлә маршрутын бирделәр. Кыштан бирле Алабуга студентлары да чакыра иде, бер уңайдан аларга да кереп чыгарга булдык. Без анда иң соңгы имтиханнары көнне барып җитәргә тиеш идек, шуңа күрә үзебезнекен биш-алты көн алдан бетердек тә, июнь ахырында юлга чыктык. Көн алама, самолетлар очмый иде, ышанычлы булыр дип пароходка гына төштек.

Былтыр җәй гастроль вакытында эссе кояш иде, без шуңа сөенеп бетә алмыйча, чәчәкле көннәр аймагында гизгән идек. Андый рәхәт быел тимәс ахры. Быел ел начар килде: май үтте – язын күрмәдек, июнь үтә - җәен күрмәдек. Бер сәбәпсез яңгыр ява дя яңгыр ява, җелекләргә үтеп салкын җил исә; шул салкында бөреләре туңып, агач яфрак ярмас, чәчәкләр чәчәк атмас сыман; көннәре дә шулай, бүртеп туңган килеш, көзгә барып ялганыр кебек иде.

Шулай да безнең кәеф начар түгел. Безнең имтихан беткән, зачет кенәгәсендәге билгеләр дә ярыйсы гына; инде без халыкка барабыз – яңа җир, яңа кешеләр күрәчәкбез, анда һәр көнебез үзенә бер имтихан булачак; сөенечен дә, көенечен дә тойган күңелләребез быелгы Идел өстедәй дулкынлана иде.

Алабугада без беренче шатлык кичердек. Бөтен шәһәргә калкып торган мәһабәт пединститутның гөмбәзле залында шаулатып үз программабызны күрсәттек. Студентлар безне урам иңләтеп гостиницага хәтле озатып куйдылар. Кәеф шәп, күңелләр күтәренке иде. Йокыдан да шундый кәеф белән уяндык. Тәрәзәләргә сыланып үткән болытлар да, шушындый көнне Чаллыга китәсе барлык та кәефебезне кыра алмады.

Х.Сарьянның “Бер ананың биш улы” әсәреннән.

**Текст**

Көзнең чатнап торган һавасы шулкадәр чиста, саф, җылы һәм коры иде. Кояш нәкъ аңа карап үзенең алтын нурларын коя, яшел уҗымнар, алар яныннан сузылган сап-сары агач полосалары, уң як болын буендагы әрәмәдә алсуланып, йә шәмәхә-кызгылт төскә кереп, йә сап-сары булып утыручы агачлар – һәммәсе, бер сагышлы моң булып, күзләр аша күңелгә тулалар иде. Табигатьтә көз булса да, инде җир өстенә тиздән кар ятачак көннәр килсә дә, Ирекнең күңелендә яз җиңеп килә иде. Уйлый, һәр ягын да бизмәнгә сала торгач, ул үзенә әйтелгән бүгенге тәкъдимнең очраклы түгеллеген аңлады. Барлык кешеләрне таң калдырырлык, аларның язмышларында  борылыш ясарлык әсәр язу хыялы аның күңелендә көчәйгәннән-көчәя бара иде. “Менә укуымны гына бетерим дә бөтен вакытымны, бөтен сәләтемне шуңа багышлыйм” дигән чаклары аның иң кадерле, берни белән алыштыргысыз илаһи мизгелләре була иде. Ләкин бит моңа ирешү өчен зур омтылышлар белән яшәргә, зур вакыйгаларның уртасында кайнарга кирәк. Мәктәп стеналары, сүз дә юк, мондый вакыйгалардан аерыла иде. Ул бер нәрсәне яхшы белә: андый әсәр тудыру өчен яңа фикерләр, кайнар тойгылар, зур рухи омтылышлар кирәк. Әсәргә аларны зур эшләр белән шөгыльләнгән шәхес кенә кертә ала. Әгәр райкомга килсә, Ирек дөньяның агышында, тормыш пульсында торачак, бүгенге киеренке тормыш вакыйгалары эчендә кайнаячак. Шул чакта гына халыкны, кешеләрне ничек яшәргә өйрәтерлек әсәр туачак. Ул әсәрнең исемен “Яңа Коръән” дип куячак.

Ф.Садриевның “Бәхетсезләр бәхете”әсәреннән.

**3 курс 5 семестр**

**Бирем.** Тексттан сүзтезмәләрне аерып алып языгыз. Аларның төрләрен билгеләгез.Синтаксик анализ ясагыз

1958 елның җәендә Аккош күленә – язучылар дачасына, Хәсән Туфанга баруыбызны теркәп куйганмын.

... Әйтер сүзе бар шикелле, Хәсән абый аулак юлга култыклап китте. Көр күңелле, җитез хәрәкәтле. Яшьлеге, дәрте ташып тора. Тиздән алтмышы тулыр дип һич уйламассың. Аны шулай шигърият яшь тотадыр, дип уйлап куям. Урман юлыннан атлый торгач, тартынып кына серен ача:

– Гашыйк булдым әле, малай... Яшь чагындагы шикелле...

Җырлар язам, мәхәббәт җырлары!

Гашыйк хәлендә иде ул, гашыйк халәтендә. Яшь аермаларыбыз онытылды, мәхәббәт серләрен бүлешкән ике яшьтәш сыман идек. Инде тартыну беткән, сөенеч уртаклашырга ашкыну гына бар.

Бәхетле иде ул, җиңел гәүдәле, очып–атлап барган, кагынып–канатланып, үз хәленә үзе гаҗәпләнгәндәй сөйләүче яшь кеше иде. Әйтерсең лә шагыйрьнең мәхәббәт кошы озак еллар читлектә ябылып ятканнан соң Аккош күлендәге якты яшеллек бәйрәме өстендә очынып уйный! Әйтерсең лә күңелдә бикләнеп–тыелып яшәгән хисләр дәррәү күтәрелеп иреккә чыккан! Ирек тулылыгын, иркенлек хозурлыгын, илһамлы бәхетен тамырларына кайнарлыгы йөгереп мәхәббәте сиздергәндер.

Тоташ булып, коеп–коеп яңгыр яуды. Куаклардан су коела. Аяк асты юеш. “Быел арышларны күрми калам, ахры..”– дигәч, Хәсән абый кыр ягына алып китте. Урманнан чыктык. Игеннәр җилле яңгырдан соң сөрлеккән, каерылып–каерылып ята. Ялтырап кояш чыкты, яңадан аякка басарлар әле, күтәрелерләр – табигатьнең үзе генә белгән яшерен көчләре бар аның!

Кичен дача йортында Хәсән абый, Илдар Юзеев, мин – өчәүләп идәндә тәгәрәшеп йокладык. Хәсән абый мөлаем, кайгыртучанлык белән урын–җирне рәтли, булышырга да өлгерә алмый каласың. Шундый гади, кече күңелле – аның янында тартынмыйча, үзеңне иркен тотасың. Соңыннан: “Тукта әле, саксыз сүз, йә кыланышым белән рәнҗетмәдемме?” – дип уйлап та куясың...

Бу очрашу Мәскәүдәге декада көннәреннән соң бер ел үткәч булды. Шагыйрь инде иркен күккә иялләшкән очар коштай иде...

Ш.Галиевның “Мәхәббәтле көннәр” әсәреннән

**Бирем**

**1.Тексттан сүзтезмәләрне аерып алып языгыз.**

**2.Аларның төрләрен билгеләгез. Синтаксик анализ ясагыз**

Халык күңеленә, рухына тәңгәл килгән әдипләр күп булмый. Аларны халык үзе сайлап ала. Ул иҗат итеп яшәгән четерекле дәверләрдә кемнәр генә телгә кереп, телдән төшмәгән. Сибгат Хәким исә һәрвакыт үз урынында. Шагыйрь язмышы гыйбрәтле. Ул беркайчан да вакланмады. Тукай, халык язмышы – гомер буе шушы биеклектә булды, рухи дәрәҗәсе шул югарылыкта булды.

Безне шигърияткә Тукай китергән, Тукай очраштырган, җан берлегебез дә Тукайда. С.Хәкимне дә мин Тукай белән хәтерлим. Тукайга багышланган поэмаларын ярты гасыр элек китапханәдән алып укуым күз алдымда. Тәэсирләрем дә истә.

Тукайга якын – күңелгә якын! Аны олылау, халык рухы белән бер итеп күрү С.Хәкимнең иҗатында гомере буе яңара торды. Тукай дип кабатласа да, шигъриятендә кабатланмады. Татар күңелендә Тукаена мәхәббәтне яңартып торган иң тугрылыклы шагыйрь ул. Бу аның рухи халәте, яшәү мәгънәсе, илһамы – януы, иманы иде.

Исемнәрен телгә дә алырга ярамаган Җәлилсез, Туфансыз чорларда Сибгат Хәким, Әхмәт Фәйзиләр Тукай – Байракны шигъриятебез символы итеп югары тотты. Чордаш, каләмдәш дуслары “онытылудан” кайта башлагач, Сибгат абый аларга киң күңелле булды – Җәлил, Туфан дип олылап күтәрде! Кирәк өчен генә түгел, яратып, җаны–тәне белән үз итеп, әдәбият даны итеп күтәрде. С.Хәкимнең олылыгы да шунда.

Татар поэзиясенең югары дәрәҗәсен кайгыртты. Әйе, аны борчыган, җанына тигән нәрсәләр аз түгел иде. Ачынып, кайчакта нәфрәтләнеп сөйләр, әмма төп бәясен югалтмас иде. “Үзем!” дип, кайберәүләр сыман бүтәннәрне төшерү хисабына күтәрелүне түбәнлек санады. Шигърият аңа – намус, вөҗдан эше, халык рухына гасырлардан килгән мираска тугрылык. Хәзер кайбер бәя бирүчеләр шагыйрь иҗатында тапларны күбрәк күрергә тырышалар. Шигърият – яктылык ул, яктысын күрә белик, яктылык кирәк күңелгә.

**4 курс 7 семестр**

**Бирем. Текстта җөмләләргә синтаксик анализ ясарга.**

**1 вариант**

Мин ул әбекәйне күптәннән беләм. Безнең ишегалдында мин белә–белгәннән бирле яши ул. Аның белән беркем дә аралашмый. Моның бик мөһим сәбәбе бар. Ул һәр көнне урамга бер гөл күтәреп чыга. Подъезд ишегендә ялтыравыклы чәй кәгазенә төрелгән гөл савыты күренү белән, ишегалдында булган кешеләр бер–берләренә карашып алалар, аннары, кем – кибеткә, кем – үз өенә, кем кая таралыша башлый. Хәтта такталар белән бүлеп алынган комлыкта уйнап утыручы бала-чага да бермәлгә тынып калгандай була. Бөтен ишегалдын сәер тынлык биләп ала. Ниндидер шомлы тынлык...

Нәкъ шулай, ишек катыннан иң элек ялтыравыклы, көмеш балкышлы кәгазьгә чорналган гөл савыты килеп чыга, аннары, куе яшел яфраклары белән дөнья тутырып, гөл үзе күренә. Бераздан шул күпереп торган яшеллек очында, күзләрне иркәләп, җете кызыл чәчәкләр пәйда була. Матур, юк, матур гына түгел, гүзәл, әкияти бер күренеш бу. Тик бу гүзәл әкият озакка бармый. Гөл артыннан ук аның иясе – теге сәер карчык үзе күзгә чалына. Кыяфәте–йөзе белән әллә ни куркыныч түгел ул. Юк–юк, бөтенләй дә куркыныч түгел! Хәтта... ниндидер мөлаемлык та бар бу әбидә. Киемнәре искедән булса да, ул бик пөхтә, чиста киенеп йөри. Ак яулыктан, яшел чәчәкләр төскә кергән, кайбер урыннарда, күп юылудан уңып, бөтенләй дә үз төсмерен югалтканнар. Аягында юка, әмма тыгыз һәм тигез итеп бәйләнгән, кыска кунычлы оекбаш, аның өстеннән ялтыравыгы тоныклана башлаган галош киеп куйган...

Димәк, татар әбие бу. Татар әбиләре генә шулай пөхтә, матур итеп, иң мөһиме, актан киенеп йөриләр. Татар әбиләре генә яулыкларының читен шулай кайтарып бәйлиләр. Татар әбиләренең йөзе генә шулай ачык, мөлаем була. Ниндидер якты, игелекле нур балкытып тора бу йөзләр. Авыз читләрен каплап, кеше күзенә тутырып карарга кыймыйча гына сөйләшәләр. Гәпләшәләр татар әбиләре...

Г.Гыйльманов “Гөлләр дә елый” хикәясеннән

## 2 вариант

Җәй башының шифалы яңгыры, тузанлы юллар өстеннән тыпырдап, җитез генә явып үтте… Иртәнге яшь кояш та таулар шикелле күкнең түренә сузылга кара-зәңгәр болытлар өстеннән ялтырап килеп чыкты. Аның яктылыгы шундый мул, нурларының түгелүе шундый дәртле, җитез иде, хәтта кояш үзе дә бу юмартлыгыннан тынычлыгын җуеп, урынында тик тора алмыйча тибрәнә һәм бер кечерәйгәндәй, бер зурайгандай булып кәренә иде. Аның әйләнәсендәге аксыл якты күк, алтын тузанында аунаган үтә күренмәле юка ефәкне кемнәндер йөгерә-йөгерә җәйгән шикелле, һаман ачыла бара, һәм ераклашкан колытларның күкрәве аның өстен сыйпап, тигезләп үткәндәй тоела иде… Яңгырның соңгы тамчылары җиргә төшеп бетәргә өлгермәс борын, салават күпере дә калыкты. Аның бер башы тау итәгендәге сыек ак томанга төренгән иген кырына терәлгән, икенче башы, киң тугай аша дугаланып, Сакмар өстенә төшкән иде.

Рәхилә, ашыкмыйча гына килеп, урамга караган кечкенә тәрәзәне ачты. Өйнең бүрәнәләренә терәлеп үскән миләш агачының яфракларыннан берничә эре тамчы тәрәзә төбендәге гөлләр өстенә коелды. Бәбкә үләннәре өстендәге, энҗе бөртекләре шикелле, нур чәчрәтеп уйнаган тамчыларның яктылыгы, яңгыр исе белән аралашып, өй эченә иңгәндәй булды…

**4 курс 8 семестр**

**Текст**

**Бирем.**

**1.Текстта тыныш билгеләренең куелышын аңлатыгыз.**

**2. Текст функциональ стильләрнең кайсы төренә карый. Җавабыгызны аңлатыгыз.**

...Теплушкаларның берсендә түбәнге сәкедә каты яралы яшь лейтенант – татар егете ята. Егетнең хәле авыр, уң аягы аның тездән югары киселгән, ә санитар поезды юлга чыккач, аңарда гангрена башланды. Менә бер тәүлек инде ул, ни йоклый, ни уяна алмыйча, ярым һушын югалткан хәлдә ята. Вакыт–вакыт ул аңына килә, шул  чакта авыр газаптан талган күзләрен ача, янында басып торган ак халатлы шәфкать туташын күрә, аның салкын кулын маңгаенда тоя. Бер мәлгә егет үзен җиңеләеп киткәндәй хис итә, хәтта уң аягы бар,

ул кычыта кебек тоела аңа... Ләкин бу хәл озакка  бармый, тагын бөтен тәне буйлап ут тарала, күзләрендә бизгәк чаткысы кабына. Бераздан егет күз кабакларын акрын гына йома һәм , һушын югалтып, яңадан эссе томан эчендә йөзә башлый. Яткан урынын да, туташның кагылуын да, хәтта шприцның очлы энәсен дә ул инде тоймый...

Шулай үлем тырнагыннан ычкына алмыйча газапланып ята егет. Врачларның өметләре аз, гангренаның никадәр хәтәр нәрсә икәнен алар яхшы беләләр. Бигрәк тә юл шартларында авыруның хәлен җиңеләйтү бик читен эш иде.

Бу кечкенә станциягә килеп туктагач, күпмедер вакыттан соң, егет тагын бер мәлгә һушына килде. Талган, инде бу дөньядан китә башлаган күзләрен ачты, вагон эченә сибелгән зәгыйфь сары яктылыкны басып торган ак халатлы шәфкать туташын күрде. Тышта вагон стенасына ышкылып кына яуган көзге вак яңгырның әкрен генә кыштырдавын ишетеп алды. Кара янып кипкән иреннәрен хәлсез ялап куйды – эчәсе, бик эчәсе килә иде аның...

Шәфкать туташы моны аңлады, алюмин кружкадан аңа бер йотым су эчерде. Егетнең рәхмәт әйтерлек хәле юк иде, ул бары аз гына җылына төшкән күзләрен туташка күтәреп, кара керфеген генә сирпеп куйды.

Ә. Еникинең "Кем җырлады?" хикәясеннән

**Бирем.**

**1.Текстта тыныш билгеләренең куелышын аңлатыгыз.**

**2. Текст функциональ стильләрнең кайсы төренә карый.  Җавабыгызны аңлатыгыз.**

Авылның исеме аның уртасыннан челтерәп аккан чишмә исеменнән алынган. Көмешлесу чишмәсе Уба тавыннан агып чыга да, кояш нурларында чагылган энҗе бөртекләредәй саф суыннан елгачык хасил итә. Суы шулкадәр чиста аның, төбендәге вак ташлар, кечкенә балык, маймычлар да көзгедәгедәй күренеп торалар. Чишмә агып төшеп Кытай җирендәге Зайсан күленнән башланган олпат Иртешкә коя. 4248 чакрымга сузылган бу олы себер елгасының юлында никадәр күп мондый чишмәләр! Ил төкерсә – күл булыр, ди халык. Әнә шундый меңләгән чишмә-елгачыклар аны туендыра, яшәү көче бирә. Көмешлесу да Чал Иртешнең уйнак нәбәрәсе кебек: кояш нурларында күзләрне чагылдырып, яшь киленнәрнең чулпы тавышларын хәтерләтеп, чылтырап көлә, назланып ага, уйнаклап боргалана да, иркә песи баласыдай, олатасының култык астына кереп, тынычлана. Мәшһүр Иртеш авылның көньягыннан үтә, ә төньягыннан ярымбоҗра булып Уба таулары сузылган. Ындыр артыннан гына кедрач башлана, ул балыклары белән дан тоткан  Йөгәр күлгә барып тоташа. Анда сап-сары алтындай тәңкәле табан балыклары дисеңме, кызыл ка-нат, усал чуртаннары – кайнап тора. Кеше күзеннән читтәрәк маймылдаган симез батар үрдәкләре өер-өер булып балык аулыйлар, камышлыкларында аккошлар бала чыгара. Көн кунганда, таң алдыннан хәйран та-маша монда: күл өстен каплап, пыр-пыр килеп төрле үрдәкләр оча. Әллә нинди хикмәтләре бар аларның да: караүрдәкләр, күгәлләр, чумгалар, чүрәкәйләр, кылкойрыклар… үз телләрендә җанашлары, балакайлары белән әңгәмә алып баралар, иркәләнәләр, сөешәләр. Бик белеп, ризыклы урынны сайлап утырганнар. Көмешлесулыларның ата-бабалары.

Я.Зәнкиев "Ялкында өтелгән мәхәббәт" әсәреннән

**5 курс 9 семестр**

**Бирем. Текстка план төзегез. План буенча эчтәлеген сөйләгез.**

**Текст**

Ике көн дәвам иткән юл мәшәкатеннән соң безгә урманда тукталып, яңгырлы көнне дошман калдырып киткән блиндажларда уздырырга туры килде.

Иртәгесен кояш күтәрелә башлау белән мине лазарет начальнигы чакыртып алды да, карта биреп, җайлы дислокация урыны эзләргә чыгарып җибәрде.

Көн аяз булырга чамалый иде.

Мин, яралары инде тәмам төзәлгән кара айгырга менеп, урман сукмаклары аша уздым да, зур юлга төштем.

Төн буе яуган сентябрь яңгыры юлны төзәткән. Үтә алмаслык комлы юл, гадәттә, яңгырдан соң яхшы-ра.

Кара йөгерек аргамак, иркен һәм такыр юлга чыгу белән, элдертеп мине алып китте. Бер айдан артык ияр күрмәгәнгә күрә, ул барлык көченә юырта һәм аны тыеп бару өчен миңа шактый көч куярга туры килә иде.

Көннең әле яңа башлануына карамастан, фронт юлында җанлы хәрәкәт. Понтон күперләре төялгән автомашиналар, брезент белән капланган "Катюшалар" бер-бер артлы көнбатышка агылалар. Юл буендагы күрсәткечләр минем нинди юнәлешкә китүемне, юлларның күпме киңлектә миналардан тазартылуын хәбәр итеп торалар. Элемтәчеләр, баганалар утыртып, телеграф чыбыклары тарталар. Дошман, авылларны яндырып, юлларга чиксез күп миналар күмеп, көнбатышка агыла. Безнең армия алга әйтеп бетергесез кызулык белән бара. Безгә, ветеринария законнарында булмаган яңа ысуллар табып, яралы һәм авыру атларга юл өстендә генә ярдәм күрсәтергә һәм күпчелеген тыл лазаретларына озатырга туры килә.

Ниләр генә күрергә һәм нинди генә вакыйгалар ишетергә туры килми монда!

Шулай моннан бер атна элек үтеп барышлый безгә бер авылда тукталырга туры килде. Әле авылга җитмәстән, аның урман артында гына булуы безне өметләндереп, күңелдә ял итү шатлыгын тудырган иде инде. Ләкин көтелмәгән хәл безнең юлыбызны тоткарлады.

Урман куелыгына керү белән, агачлар арасыннан каршыбызга ниндидер бер яшь кеше килеп чыкты. Иске чикмәннән, **яланбаш**, яланаяк, яшь чырайлы, ияген сирәк сары сакал баскан бу кеше юл уртасында чыкты да, кулларын күтәреп, безнең юлны бүлдерде. Атлар туктап калдылар, без арбалардан төшеп әлеге билгесез кеше янына ашыктык.

А.Расихның "Сугыш сәхифәләреннән" романыннан

**Текст**

Кешеләргә ярдәмчел булу – талант, юмартлык. С.Хәким юмарт булды, җырларын халыкка өләште, рәхәтен күрегез, кинәнегез! Сөенерсез дә, әрнерсез дә – гамьсез генә булмассыз. Еллар үткән саен хискә байый, тормыш фәлсәфәсе тирәнәя барган борчулы, уйчан шигырьләре, поэмалары...

Шагыйрь әдәби алмашка ярдәмгә юмарт булды, әдәбият чикләрен үтеп җырчылар, композиторлар, сәнгатьнең барлык өлкәләрен кайгыртып, күз уңыннан төшермәде. Ни өчен вакытын, кәефен сарыф итә–итә бар тармакны колачларга тырышкан ул? Җавапның берсе шулдыр: аның күз алдында, утызынчы еллар азагыннан башлап, Ватан сугышы чорында дәвам итеп, әле соңыннан да милли мәдəниятебезгә хезмәт итүче күпме фидакарьләр кырылган. Тормыш бушлыкны кичерми, бушлык халык күңеленә күчмәсен, алмашка яңа буыннарны – яңа яшьләрне үстерү кирәк, дигән. Әлбәттә, мондый уй аны гына борчымагандыр. Җаваплылыкны үз өстенә мәшәкатьле эш итеп алучылар сирәгрәк. С.Хәкимнең исә ул иҗатыдай җан тарткан вазыйфасы иде. Бик күпләргә ярдәм кулы сузды. Таләпчән иде, талантларны күрә килде. Киң күңеллелеген файдаланучы әрсезләр дә булмады түгел. Тик алар бер нәрсәне онытты: шагыйрь сүзен акларлык итеп яшәргә, иҗат итәргә кирәк – шуңа омтылганда гына үсә кеше. Остаз әнә шул омтылышка стимул тудыра: үс, күтәрел, миннән фатиха, ди. Күренсен сәләте, тырышсын. Һәркем үзенчә ачылырга мөмкин, бәлкем әдәбиятка өлеше булыр? Син инде үзең кара, кайсын сайлыйсың: зур таләпле кыен юлнымы, әллә түбәнрәк планга куеп, тәбәнәк "биеклек"неме?

Шәүкәт Галиевның "Остаз сабаклары" әсәреннән

**5 курс 10 семестр**

*Бирем 1. Язучылар үзләренең әсәрләрендә күрсәтелгән сүзләрнең кайсысын кулланганнар? Җәя эчендәге сүзләрнең берсен кулланыгыз.*

1.Акыл (зәгыйфьләнгән, талган, арган), тән дә ватылып, йончып беткән (М.Җәлил) 2. Наташа Нәфисәнең (йончыган, алҗыган, талчыккан) кыяфәтенә, өч көн эчендә күзгә күренеп ябыккан (төссез, аксыл, зәңгәрсу, борчулы) йөзенә карап алды. (Г. Бәширов) 3. Гитлерга нәләт укый-укый (талчыккан, хәлсезләнгән, йончыган), тәмам (арып беткән, хәлдән тайган) авыр гәүдәләрен көч-хәл белән сөйрәп, сугу машинасы янына җыелалар. (Г. Бәширов) 4. Сибәләп кенә үтеп киткән төнге яңгырдан соң гаҗәеп (матур, гүзәл, ачык, аяз) таң атты (Г. Әпсәләмов)

*Бирем 2. Җөмләләрдә стиль төгәлсезлекләренә игътибар итегез.Аларны төзәтегез һәм аңлатып бирегез.*

1.Яшелчә җитештерү белән кызыксынучы белгечләр аны файдалану мәсьәләсендә үз тәкъдимнәрен әйтерләр һәм озакка сузмыйча эшкә башларлар дип ышанырга кирәк. 2.Укучыларның күбесе “4” һәм “5” билгеләренә генә өлгерүче педагоглар бездә шактый. 3. Ул күңеле нечкәрүдән җылынып киткән күзләре белән аңа һәм балаларына карады. 4. Артистлар югары профессиональ дәрәҗәдә уйныйлар. 5. Көздән мең гектар арыш чәчелде. Уҗым көр. 5. Терлекче һәм игенче , авыл хуҗалыгы производствосының терәге булу белән бергә, зур хәрефтән – кеше.

## 6 курс 11 семестр

### “Фонетика”, “Лексикология”, “Фразеология” бүлекләре буенча

1.Татар һәм рус телләренең сузык һәм тартык системасының таблицасын төзегез. Аларны чагыштырып, аермаларын күрсәтегез.

2. Татар һәм рус телләрендә икешәр җөмлә алып, аларны транскрипциядә күрсәтегез.

3.Татар һәм рус телләрендә сузыклар һәм тартыклар өлкәсендә барган күренешләрне билгеләгез. Ике телнең дә үзенә генә хас күренешләрен ачыклагыз.

4. Түбәндә бирелгән сүзләрдә басымнар куеп чыгыгыз. Ике телдә дә басымның ролен билгеләгез. Орфоэпик сүзлекләр буенча үзегезне тикшерегез.

*Авыл, урман , язылыз, килмәде, һичкем, һәммә, татарча, шундый, өлгер, ләкин, аюдай, кайда, ниндидер, бармагансың, балалар, байрак;*

*Километр, красивый, намерения, некоторый, столяр, средство, свободный, расположить, статуя, хозяин, каталог, инструмент, изобретение, досуг.*

**5.** Татар һәм рус теленең аңлатмалы сүзлекләреннән бишәр бер мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләргә мисаллар китерегез. Мәгънәләрен аңлатыгыз.

6. Татарча бирелгән фразеологик берәмлекләрнең русча эквивалентларын (булса) китерегез. Фразеологик сүзлекләрдән тикшерегез.

*Утсыз төтен булмый, ут чәчү, төпсез мичкә, күңел бушату, күңел йомшару, күңелең киң булса, тар җиргә дә сыясың, колак кагу, бөкрене кабер генә төзәтә, исе дә китми, урманга утын төяп бару, кесәгә сугу, юлыңа ак җәймә, телсез калу, ачу тоту, акылга утыру, керфек какмау, күз карасы кебек саклау, канат астына алу, күздән утлар күренү, түбәсе күккә тию, колакларны торгызу, көймәсе комга терәлү.*

## Перечень вопросов для оценки уровня сформированности компетенции ОПК-1 на этапе «Навыки»

## Тесты

### 1 курс 1 семестр

1. **Бу сүздә нинди хәреф төшеп калган**
   ***тәнк...ть***
   а) и;
   б) ый;
   в) ы;
   г) й

**2. *Көзге, күзсез, әнкәй, унбер* сүзләренең язылышы кайсы орфографик принципка туры килә?**

а) график;
б) тарихи-традицион;
в) морфологик;
г) фонетик.

**3. Сүзләрнең элекке язылышын саклап калу ул-**

а) фонетик;
б) график;
в) морфологик;
г) тарихи-традицион.

**4.** ***Демократия, реставрация, конфронтация*** **сүзләренең язылышы**

а) фонетик;
б) график;
в) морфологик;
г) тарихи-традицион принципка нигезләнгән.

**5. Кайсы рәттәге сүзләрдә һ языла?**

а) ил...ам, шә...әр, ...әйкәл, ка...арман
б) бә...ет, шә...ес, ...ава, ...әлак
в) ...ис, ..әм, ба...адир, ...әзер
г) да...и, ...ат, ...аман, ...әрвакыт.

**6. Татар алфавитында ничә хәреф?**

а) 33; ә) 39; б) 42.

**7. Татар телендә сүз башындагы [йо], [йө] дифтонглары**

а) ***й*** һәм ***о, й*** һәм ***ө*** хәрефләре белән белдерелә;
ә) ***ё*** хәрефе белән белдерелә;
б) ***е*** хәрефе белән белдерелә.

**8. Кайсы кагыйдә дөрес?**

а) [w] сүз башында ***в*** хәрефе, сүз азагында ***у*** хәрефе белән белдерелә;
ә) [w] татар сүзләрендә ***у*** хәрефе, алынмаларда ***в*** хәрефе белән белдерелә;
б) [w] иҗек баашында ***в*** хәрефе, иҗек азагында ***у, ү*** хәрефләре белән белдерелә.

**9. Татар телендә *о, ө* хәрефләре:**

а) сүзнең беренче иҗегендә генә языла;
ә) сүзнең икенче иҗегендә языла;
б) сүзнең төрле иҗекләрендә дә язылырга мөмкин.

**10. Кайсы рәттә бирелгән сүзләр сызыкча аша язылалар?**

а) ак (кош), сабан (туй), гөл (җимеш)
б) эт (шомырты), тимер (юл), каен (җиләге)
в) табак (савыт), ут (су), ата (ана)
г) ал (япкыч), кул (яулык), көн (чыгыш)

**1. [’] (һәмзә) нинди хәрефләр белән белдерелергә мөмкин:**

а) ***һ, х*** хәрефләре белән;
ә) ***э, ь, ъ*** хәрефләре белән;
б) ***ь, ъ*** хәрефләре белән.

**2. *ь* хәрефе кайсы очракта аеру билгесе булып килә?**

а) рус теленнән кергән сүзләрдә;
ә) алдагы иҗекләрнең нечкәлеген белдергәндә;
б) кушма сүзләрдә икенче тамыр ***я, ю, е*** хәрефләренә башланса.

**3. [гъ], [къ] авазлары**

а) *г, к* хәрефләре белән белдерелә;
ә) *г, к* хәрефләреннән соң калын сузык хәрефләре яки **ъ** хәрефе белән белдерелә;
б) **ъ** хәрефе белән белдерелә.

**4. Кайсы сүзләр юлдан юлга дөрес күчерелгән?**
а) ка-ләм, дикъ-кать;
ә) а-ла-чык, ту-ар;
б) дик-ъкать, гыйб-рәт-ле.

**5. Кайсы рәттәге сүзләрнең язылышлары дөрес?**
а) шәһес, дахи, бәһет;
ә) мәхәббәт, һаман, каһарман;
б) хәйкәл, һәзер, һәл.

**6. *Кор...ән, тәк...дим, кул...яулык.* Күп нокталар урынына нинди хәрефне язарга кирәк?**
а) **ь** билгесен;
ә) **ъ** билгесен;
б) берниндИ хәреф тә язылмый.

**7. Фонетик принципка нигезләнгән язылышны күрсәтегез.**
а) сәгать, табигать, сәнгать;
ә) бишбармак, өчпочмак, тугай;
б) алма, агач, утыргыч.

**8. Морфологик принципка нигезләнгән язылышны күрсәтегез.**
а) тәмле, көнбагыш, унлап;
ә) тәнкыйть, гади, тиңдәш;
б) роль, кино, театр.

**9. Тарихи-традицион принципка нигезләнгән язылышны күрсәтегез.**
а) 9 нчы, 1 нче, сурәт, әмма;
ә) елъязма, көньяк, дөнья;
б) болыт, төтен, тизйөрешле.

**10. График принципка нигезләнгән язылышны күрсәтегез.**
а) этәч, сарык, үгез;
ә) тәэссорат, мәхәббәт, көннәр;
б) металл, клуб, профессор.

**11. Дифференциацияләнгән принципка нигезләнгән язылышны күрсәтегез.**
а) Айтуган, өмет, байрак;
ә) буяу, буявы, яшәү, яшәве;
б) грамматика, шәһәр, урманнар.

**12. Кайсы рәттәге язылыш дөрес?**
а) Башкорт Дәүләт университетының Стәрлетамак филиалы;
ә) Башкорт Дәүләт Университетының Стәрлетамак Филиалы;
б) Башкорт дәүләт университетының Стәрлетамак филиалы.

**13. Кайсы рәттәге язылыш дөрес?**
а) календарьләр, кофене, Томскка, гербарийгә;
ә) календарьлар, кофены, Томскига, гербарийга.
б) календарьлар, кофене, Томскийга, гербаригә.

**14. Кайсы рәттәге язылыш дөрес?**
а) калынырак, көлеберәк, агырак;
ә) калынрак, көлепрәк, акрак;
б) калынрак, көлебрәк, аграк.

**15. Кайсы рәттәге язылыш дөрес?**
а) язырга, атырга, янырга, элер, тишер;

ә) онытырга, китерер, атарга, көләр, үтәргә;
б) язарга, көлергә, онытарга, тишергә.

**16. Кайсы рәттәге язылыш дөрес?**
а) халык-ара, биш алты, көннәрдән беркөнне;
ә) халык ара, бишалты, көннәрдән-бер-көнне;
б) халыкара, биш-алты, көннәрдән бер көнне.

## 1 курс 2 семестр

1. Татар тел белеменең фонетика өлкәсендә эшләгән галимнәрне күрсәтегез
а) Ф.Ә. Ганиев, Ф.С. Сафиуллина;
б) М.З. Зәкиев, Ф.М. Хисамова;
в) Г. Шәрәф, Х.Х. Сәлимов;
г) Г.Х. Алпаров, В.Х.Хаков.

**2. Урта күтәрелешле сузыкларны күрсәтегез**
а)[у], [ү], [и]
б) [о], [ө], [ы]
в) [а],[ә]

**3. Ирен-теш тартыкларын күрсәтегез**
а) [п], [б], [м], [w]
б) [в], [ф]

**4. *Ашъяулык* сүзендә**
а) 8 хәреф, 7 аваз
б) 7 хәреф, 7 аваз
в) 6 хәреф, 7 аваз
г) 8 хәреф, 8 аваз

**5. Телнең горизонталь юнәлештәге хәрәкәтенә карап, сузыклар**
а) ике төркемгә бүленә
б) өч төркемгә бүленә
в) дүрт төркемгә бүленә

**6. Алгы рәт сузыкларын күрсәтегез**
а) [ә], [ө], [е], [ү], [и]
б) [а], [ы], [о], [у]

**7. *[в]* авазы**
а) шаулы, өрелмәле, яңгырау, тел-теш авазы
б) шаулы, өрелмәле, яңгырау, ирен-теш авазы

**8. *[ә]* авазы**
а) түбән күтәрелешле, иренләшмәгән, арткы рәт сузыгы
б) түбән күтәрелешле, иренләшмәгән алгы рәт сузыгы

**9. Хәреф саны аваз саныннан күбрәк булган сүзләрне күрсәтегез**
а) борын, бишьеллык, ашъяулык, бөре, бодай
б) яңа, кием, яланаяк, суыткыч, саескан
в) кагыйдә, ягъни, тәгъбир, мәсьәлә

**10. Сүз яки иҗек ахырында килгән яңгырау [з] яңгырау тартыкка башланган иҗек (тиз-лек) яки сүз алдыннан (тиз йөри) килгәндә**

а) саңгыраулаша
б) яңгыраулаша
в) төшеп кала
г) үзгәрми

**11. Татар телендә алынма сүзләрдә генә кулланыла торган тартыкларны билгеләгез**
а) [н], [р], [й], [н]
б)[к], [г], [л], [м]
в) [б], [д], [т],[з]
г) [в], [ц], [щ]

**12. Кайсы рәттә барлык сүзләр дә сонантларга тәмамланалар?**
а) кул, май, җәяү;
б) бай, эшли, көл;
в) таң, әнкәй, Галиев;
г) тормыш, ил, ир.

**13. Кайсы рәттә барлык сүзләр дә яңгырау тартыкка тәмамланалар?**
а) кул, имән,таж;
б) бай, эшләү, көз;
в) гараж, әнкәй, Галиев;
г) карар, бал, бияләй.

**14. *Смола* сүзе татар теленә кергәндә нинди үзгәреш кичергән?**
а) протеза;
б) эпентеза;
в) редукция;
г) ассимиляция

**15. *Шляпа* сүзе татар теленә кергәндә нинди үзгәреш кичергән?**
а) протеза;
б) эпентеза;
в) редукция;
г) ассимиляция

**16. Сингармонизм законы нәрсәне белдерә?**
а) тартыкларның ярашуын;
б) сузыкларның ярашуын;
в) сузык һәм тартыкларның ярашуын.

**17. Ирен гармониясе кайсы сузыкларга бәйле?**
а) а, ә; б) и, е; в) о, ө

**18. Татар телендәге борын тартыкларын билгеләгез**
а) [ж], [w], [h]
б) [м],[н], [ң]
в) [д], [ж], [җ]
г) [б], [в], [з]

**19. Татар телендәге тартык авазларның саны?**
а) 25; б) 26; в) 27; г) 28.

**20. Кайсы сүздә тулы ассимиляция күзәтелә?**
а) унбиш;
б) төтен;
в) әнкәй;
г) ун көн

## 2 курс 3 семестр

**1. Түбәндәге шигырь юлларында омонимның кайсы төре файдаланылган.**

*Без безсез яшәмибез,*

*Безсез без эшләмибез.*

*Итекче без өчебез,*

*Өчебезгә - ике без (Ш.Галиев).*

а) омограф;

б) омофон;

в) омоформа;

**2. “Окказионализм” нәрсә ул?**

а) очраклы сүз;

б) искергән сүз;

в) яңа сүз;

г) җаваплар дөрес түгел.

**3. Кайсы архаизмның синонимы дөрес билгеләнмәгән?**

а) инсан – кеше;

б) ут – үлән;

в) хөррият – ирек;

г) гамәли – тырыш.

**4. Кайсы неологизмның мәгънәсе дөрес аңлатылмаган?**

а) вампир – кан эчүче;

б) дисплей – компьютер экраны;

в) спикер – спортның бер төре;

г) киллер – заказ буенча үтерүче.

**5. Кайсы алынманың татарча синонимы дөрес күрсәтелмәгән?**

а) мемуар – истәлек;

б) анализ – нәтиҗә;

в) темп – тизлек;

г) скульптор – сынчы.

**6. Кайсы сүз янына *-ханә* компоненты өстәп булмый?**

а) оста;

б) мирас;

в) хисап;

г) кунак.

**7. Кайсы фразеологизмның мәгънәсе дөрес билгеләнмәгән?**

а) телгә килү – сөйли башлау;

б) телгә килү – аңга килү;

в) телгә килү – ызгышу;

г) телгә килү – уртак фикергә килү.

**8. Фразеологизмны билгеләгез.**

а) телен йоту;

б) ризык йоту;

в) су йоту;

г) чәйнәп йоту.

**9. Кайсы фразеологизмнар антоним түгел?**

а) уртак тел табу – борчак пешмәү;

б) агач кул – куян йөрәкле;

в) аркылы төшү – юл кую;
г) ахирәт дус – җан дошманы.

**10. Кайсы фразеологизмның русча эквиваленты дөрес билгеләнмәгән?**

а) алтын куллы – мастер на все руки;
б) кәкре каенга terәтү – обвести вокруг пальца;
в) телеңне йотарсың – аршин проглотил;
г) балавыз сыгу – глаза на мокром месте.

**11. Кайсы фразеологизмнарның мәгънәсе туры килми?**

а) серкәсе су күтәрмәү – үпкәләү;
б) табан ялтырату – качу;
в) утлы табага бастыру – мактау;
г) баш вату – уйлау.

**12. Фразеологизмнарны күрсәтегез**

а) чикләвек вату;
б) ваза вату;
в) баш вату;
г) тәрәзә вату.

**13. Фразеологизмның дөрес тәрҗемәсен табыгыз.**

***Үз сүзендә тору***

а) стоять на своем
б) дать слово
в) начать разговор
г) болтать лишнего

**14. Мәкальнең дөрес дәвамын күрсәт**

Үзең яхшы, ...

а)үзеңнән сүзең яхшы
б)үзеңнән күзең яхшы
в)үзеңнән телең яхшы
г)үзеңнән йөзең яхшы

**15.Теләсә нинди телдә сүзлекләр төзү белән кайсы тармак шөгыльләнә?**

а) фразеология
б) этимология
в) лексикография
г) лексикология

**2 курс 4 семестр**

**1. Түбәндәге сыйфатлар нинди төркемчәгә карый?**

*җәйге ял, иртәнге аш, карлы яңгыр, сәяси караш*

а) асыл
б) нисби

**2. Сыйфат сыйфатланмыштан башка кулланылганда …**

а) исемләшә; ләкин тартым, килеш белән төрләнми.
б) исемләшә; сан, тартым, килеш белән төрләнә.

**3. Түбәндәге саннарның төркемчәсен билгеләгез.**

*Дүрт-биш, җиделәп, унлап.*

а) тәртип
б) бүлем
в) чама

г) җыю

**4. Мәгънә һәм вазифаларына карап, алмашлыклар ..**

а) 5 төркемчәгә бүленә

б) 6 төркемчәгә бүленә

в) 7 төркемчәгә бүленә

**5. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыль кушымчалары:**

а) –ыр, -ер, -ар, -әр, -р;

б) –ачак, -әчәк, -ячак, - ячәк

в) –ган, -гән, -кан, -кән

г) –ди, -де, -ты, -те

д) –а, -ә, -ый, -и

**6. Хикәя фигыльнең ничә заман формасы бар?**

а) биш

б) алты

в) тугыз

**7. Сыйфат фигыль заман белән …**

а) төрләнә

б) төрләнми

8**. Түбәндәге фигыльләрнең кайсылары хәл фигыльнең 4 төренә карый:**

а) сөйли-сөйли, атлый-атлый

б) күргәнче, сөйләгәнче, барганчы

в) киләсе, җырлыйсы, укыйсы

**9. Түбәндәге фигыльләр кайсы юнәлештә бирелгән?**

*юылу, бизәлү, сайлану*

а) йөкләтү юнәлеше

б) уртаклык юнәлеше

в) төшем юнәлеше

г) кайтым юнәлеше

д) төп юнәлеш

**10. Түбәндәге җөмләләрнең кайсысында сыйфат фигыль бар?**

а) Тырышкан табар, ташка кадак кагар. (Мәкаль)

б) Тәрәзә башларына күгәрченнәр оялаган. (М.Маликова)

в) Күңелдәге теге авырлык һаман да бетмәгән була. (М.Маликова)

г) Ул катлаулы мәсьәләне чишәргә керешкән.

**3 курс 5 семестр**

**1. Кабатлаулы үткән заман фигыльләрен күрсәтегез**.

а) алды, язды, укыды

б) ала идем, укый идең

в) ала торган иде, сөйли торган иде

г) кайткан, йөгергән, уйнаган.

**2. җыючы теркәгечләрне күрсәтегез**.

а) ләкин, ә, бәлки, әмма, тик, исә

б) һәм, да, дә, та, тә, янә, ни … ни

в) я, яки, яисә, әле - әле

**3. Кабатлаулы үткән заман фигыльләрен күрсәтегез.**

а) алды, язды, укыды

б) ала идем, укый идең

в) ала торган иде, сөйли торган иде
г) кайткан, йөгергән, уйнаган.
**4. Җыючы теркәгечләрне күрсәтегез рсәтегез.**
а) ас, өс, ян, як, эч, тыш, буй, ал, арт.
б) тиеш, кирәк, ярый.
**5. Түбәндәге исемнәр кайсы төркемгә карый?**
Каләм, сәгать, урман, болын
а) абстракт мәгънәле
б) конкрет мәгънәле
**6. Исемнәр …**
а) тартым, сан белән төрләнә
б) сан, килеш белән төрләнә
в) килеш, сан, тартым белән төрләнә
**7. Түбәндәге сыйфатлар кайсы төркемчәгә карый?**
Көзге яңгыр, карлы буран, сәяси караш
а) асыл
б) нисби
**8. Сыйфатларда чагыштыру дәрәҗәсе** …
а) бер әйбердәге билгеләмә башка әйбергә караганда чагыштырмача артык булуын белдерә
б) гадәти билгесен белдерә
в) гадәттәгедән бераз ким булуын белдерә
г) билгенең башка әйбердәге билгедән бик күпкә артык булуын белдерә
**9. Санның мәгънәви ягыннан төркемчәләре ...**
а) өч
б) дүрт
в) биш
**10. Алмашлыклар кайсы төркемчәгә карыйлар:**
*барысы, һәммә, үз, бар, һәр*
а) билгесезлек
б) билгеләү
в) күрсәтү
г) юклык
д) сорау
**11. Алмашлыклар ясалышы ягыннан …**
а) тамыр, ясалма төрләргә бүленәләр
б) тамыр, ясалма, кушма төрләргә бүленәләр
б) тамыр, ясалма, кушма, тезмә төрләргә бүленәләр
г) тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә төрләргә бүленәләр
**12. Түбәндәге фигыльләр кайсы заманга карый:**
*яза идем, кайта идем, сөйли иде*
а) билгеле үткән заман
б) билгесез үткән заман
в) тәмамланмаган үткән заман
г) күптән үткән заман
д) кабатлаулы үткән заман
**13. Теләк фигыльнең …**
а) беренче заты гына бар
б) беренче, икенче заты бар

в) беренче, икенче, өченче заты бар

**14. җөмләдә калын хәрефләр белән бирелгән сүз фигыльнең кайсы формасына карый.**

*Таң нурына* ***коенган*** *чәчәкләр бәхет турында сөйли. (М.Маликова)*

а) хәзерге заман сыйфат фигыль

б) үткән заман сыйфат фигыль

в) үткән заман хикәя фигыль

г) күптән үткән заман хикәя фигыль

**15. Инфинитив түбәндәге кушымчалар белән ясала:**

а) –тыр, -тер, -дир, -дер

б) –ырга, -ергә, -рга, -ргә, -арга, -әргә

в) –у, -ү

г) –гач, -гәч, -кач, -кәч

**16. Рәвешләр кайсы төркемчәгә карыйлар?**

*әкрен, тиз, җәяү, кинәт*

а) күләм-чама

б) охшату-чагыштыру

в) саф

г) вакыт

**17. Бәйлек сүзләр …**

а) тиеш, юк, бар, кирәк

б) ас, өс, як, ян, эч, тыш, буй

**18. Сүз төркемнәренең исемгә күчүе ничек атала?**

а) субстантивация

б) адвербиализация

в) адъетивизация

**19.**Кәгазь алды, каләмен карага манды җөмләсендә ***карага*** сүзе...

а) сыйфат

б) исемгә күчкән сыйфат

в) исем

**20. Сүз төркемнәренең сыйфатка күчүе ничек атала?**

а) субстантивация

б) адвербиализация

в) адъетивизация

**4 курс 7 семестр**

**1. Сөйләмнең барлык үзенчәлекләрен чагылдыручы берәмлекләргә**...

а) сүзләр һәм сүзтезмәләр;

б) текст һәм җөмлә;

в) сүзтезмә һәм җөмләләр;

г) сүзләр һәм җөмләләр керә.

**2. Хәбәрлек...**

а) сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәте;

б) сөйләмнең хәбәр итү үзенчәлеге.

**3. Трансформацион синтаксис...**

а**)** җөмлә төзелешен үзгәртеп төзү**;**

б) төрле диалектлардагы җирле сөйләм;

в) сөйләмне форма ягыннан өйрәнә;

г) сөйләмне семантика ягыннан өйрәнә.
**4. Формаль синтаксис...**
а) җөмләнең аралашу процессындагы функциясе;
б) сөйләмдә семантика-фикер төзелешен;
**в)** сөйләмне форма ягыннан тикшерә**.**
**5.Иярткүле бәйләнеш...**
а) сүзләр бер-берсенә буйсынып килә;
б) сүзләр узара тигез хокукта булалар;
**6.Иярткүле бәйләнеш ничә төрле була?**
а)ике төр;
б)өч төр;
в) дүрт төр;
г) биш төргә бүленә;
**7.Аныклаулы мөнәсәбәт...**
а)иярүче сүз, ияртүче сүздән соң килеп, аңа төгәллек, аныклык бирә;
б) иярүче сүз ияртүче сүзнең мәгънәсен аерып, конкретлаштырып бирә;
в) иярүче сүз(хәбәр) ияртүче сүз (ия) белдергән төшенчә турында яңалык хәбәр итә;
8. **Кызларның, бигрәк тә Нуриянең**, күзләре сокланудан ялтырап китте (Г.Әпсәләмов) җөмләсендә
а) хәбәрлекле
б) төгәлләүле
в)аныклаулы мөнәсәбәт
**9. Исем сүзтезмәләрнең төрен билгеләргә: а) исемле исем сүзтезмә; б) сыйфатлы исем сүзтезмә; в) рәвешле исем сүзтезмә; г) фигыльле исем сүзтезмә**
1.курыккан төс;
2. моңсу уйлар;
3.уйларга исәп;
4. Тимерче Мостафа;
5.туктаусыз хезмәт;
6.ышанычлы кеше;
7.утын кискән пычкы;
8.җырдай тормыш;
9.ышанычлы кеше;
10. татарча спектакль.
**10. Сүзтезмәләрнең төрен билгеләргә**
(а-сыйфат сүзтезмәләр, б- рәвеш сүзтезмәләр, в- алмашлык сүзтезмәләр, г- хәбәрлек сүзтезмәләр)
1. артык тупас;
2. сиңа мөмкин;
3. су кебек кирәк;
4. эш өчен яхшы;
5. төлкедәй хәйләкәр;
6. дусларымнан тегесе;
7.поездан да тизрәк;
8. миңа юк;
9.һаман тирән;
10. шактый зур

**4 курс 8 семестр**

**1. Җөмләнең иярчен кисәкләре...**
а) аергыч, ия, хәбәр, тәмамлык;
б) хәл, аергыч, хәбәр, тәмамлык;
в) аергыч, хәл, тәмамлык;
г) аергыч, хәл, тәмамлык;аныклагыч;
**2. Татар телендә җөмлә кисәкләренең саны:**
а) 6
б) 7
в) 8
г) 10
**3.Җөмләнең иярчен кисәкләре...**
а) аергыч, ия, хәбәр, тәмамлык;
б) хәл, аергыч, хәбәр, тәмамлык;
в) аергыч, хәл, тәмамлык;
г) аергыч, хәл, тәмамлык;аныклагыч;
**4. Сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерүче кисәкләр**
а) ия, хәбәр;
б) эндәш, кереш сүзләр;
в) хәл, аныклагыч;
г) хәл, аергыч;
**5. Хәбәрләрнең төрләре...**
а) гади һәм кушма;
б) гади һәм тезмә;
в) гади, тезмә, кушма;
**6. Түбәндәге җөмләләрдә тезмә фигыль хәбәрләрне (а) һәм кушма фигыль хәбәрләрне (б) аерыгыз**.
1. Мин китәргә булдым (Г. Гобәй);
2. Хәлимнең эченә җылы керде (И. Гази);
3. Мәликә апа бөтенләй аяктан калды (Д. Аппакова);
4. Егет җырлап җибәрә (Ә. Еники).
**7. Түбәндәге җөмләләрдә гади исем хәбәрләрне (а), тезмә исем хәбәрләрне (б) кушма исем хәбәрләрне (в) аерыгыз**
1. Беребез кояш чыгышында, беребез баешларында (җыр);
2. Ай да гел синең төсле (җыр);
3. Безнең план зурдан (К. Тинчурин);
4. Бу мәһабәт бина- Казан дәүләт университеты;
5. Сезнең хәлләр шәптән түгел (Г. Бәширов);
**8. Сизенәм: егетләрнең урнашырга исәпләре юк түгел (Ф. Хөсни) җөмләсендә урнашырга сүзе..**
а) хәл;
б) хәбәр;
в) аергыч;
г) тәмамлык;
**9. Хәл төрләренең саны...**
а) 6;
б) 7;
в) 8;
г) 9.
**10. Рәхимовлар** гаиләсе белән катышу Хәятка беркадәр үзгәреш бирми кала алмады (Ф.Әмирхан) җөмләсендә калын хәрефләр белән бирелгән сүз-

а) тәмамлык;
б) аергыч;
в) хәл.
**11.** Габдулла дөньяның әчесен – төчесен **җитәрлек** татыган кеше **(И.Гази)** җөмләсендә калын хәреф белән бирелгән хәл...
а) урын хәле;
б) вакыт хәле;
в) рәвеш хәле;
г) күләм хәле;
**12.** ***Кайту белән*** *эшкә тотынды* **җөмләсендә хәл...**
а) сәбәп;
б) максат;
в) вакыт;
г) рәвеш хәле;
**13.** ***Кояш бик югары күтәрелгән иде*** **(Г.Ибраһимов) җөмләсендә югары сүзе...**
а) урын хәле;
б) вакыт хәле;
в) күләм хәле;
г) рәвеш хәле;
**14. Кайсы җөмлә кисәге бары тик ияртүче кисәктән соң гына килә?**
а) аергыч
б) тәмамлык
в) хәл
г) аныклагыч
**15. Сөйләүченең сөйләм эчтәлегенә мөнәсәбәтен белдерүче сүзләр...**
а) кереш сүзләр
б) эндәш сүзләр
в) модаль сүзләр
г) аныклагычлар
**16. Җөмләнең иясе белән хәбәре арасында...**
а) атрибутив мөнәсәбәт
б) предикатив мөнәсәбәт
в) объект- субъект мөнәсәбәте
г) ачыклаулы мөнәсәбәт
**17. Җөмләләрдә туры (а) һәм кыек (б) тәмамлыкларны аерыгыз.**
А). Беренче пуля аның башыннан яралады (Г. Әпсәләмов )
б) Бакчаны таштан арындырды (И. Гази).
в). Гаризасына кадәр язып китерделәр (Г. Бәширов )
г)Казларга кадәр каңгылдашалар (И. Гази )
д). Һәрбер мещан төтен җибәрергә, мактанырга ярата (К. Тинчурин )

**5 курс 9 семестр**

**1. Кайсы җөмләдә стилистик хата бар?**
а) Бу галстук синең кайсы күлмәгең белән барыр икән?
б) Гомерләр уза икән ул!
в) Ләкин мин боларны кайдан алыйм?
**2. Кайсы җөмләдә стилистик хата бар?**
а) Тышта ниләр бар икән?
б) Храм музейга әверелдерелә.

в) Шомыртлар чәчәк ата
г) Бәхет дигәннәре шулдыр инде ул!
3. Татар телендә кайсы пар сүзләр кулланылмый
а) мәхәббәт-мәһабәт
б) ахыры-ахры
в) таләп-тәләп
**4. Татар телендә кайсы пар сүзләр юк**
а) гыйбрәт-гыйбарәт
б) тәкбир-тәгъбир
в) хуш-һуш
г) тәэсир-тәкъсир
**5. Кайсы алынма сүзнең мәгънәсе дөрес аңлатылмаган?**
а) матдә – җисем, әйбер
б) тәэсир итү – йогынты ясау
в) тәгъбир – алланы зурлау
г) нәшер итү – матбугатта бастыру
**6. Кайсы рәттәге фразеологизмнарны антоним итеп файдаланып булмый?**
а) ахирәт дус – җан дошманы
б) аркылы төшү – юл кую
в) сукыр да күрерлек – сукыр гына күрмәс
г) уртак тел табу – борчак пешмәү
**7. Кайсы сүзтезмә дөрес тәрҗемә ителгән?**
а) янгын күзәтелде
б) авыл кешесе
в) костюм-чалбар
г) быелгысы елда
**8. Кайсы рәттәге фразеологизмнарны синоним итеп файдаланып булмый?**
а) тамактан үтмәү, тамакка үтмәү
б) диннән язу, деннән язу
в) өскә салкын су сипкән кебек, башка кайнар су койган күк
г) сүз йөртү, сүз уйнату
**9. Нәрсә ул стилистика?**
а) язучының тел үзенчәлекләрен өйрәнүче фән
б) төрле язу һәм сөйләү стильләре
в) тел белеменең тел һәм сөйләм стильләрен өйрәнүче бүлеге
г) тел һәм сөйләмнең сурәтләү чараларын өйрәнүче фән
**10. Кайсы стиль авторның барлык уй-фикерләрен, телнең бөтен байлыгын чагылдыра?**
а) хатлар стиле
б) матур әдәбият стиле
в) фәнни стиль
г) бер стиль дә чагылдырмый
**11.Тиндәш кисәкләре арасында нинди тыныш билгеләре куела?**
а) нокталы өтер
б) сызык
в) ике нокта
г) өтер
**12.Бу җөмләдә өтерләр ни өчен куелган?**
Болында ал, кызыл, зәңгәр чәчәкләр үсә.
а) тиндәш кисәкләр

б) кереш сүзләр
в) аныклагычлар янында

**13.Нинди тыныш билгесе куелмаган?**

Ишек тәрәзә идән барысы да әйбәт юылган.

а) ике нокта;
б) сызык;
в) ике урында өтер һәм сызык;
г) җәя.

**14. Ни өчен өтер куелган?**

Әле яңгыр ява, әле кар ява.

а) кереш сүз;
б) эндәш сүз;
в) тиндәш кисәкләр;
г) теркәгечле тезмә кушма җөмлә.

**15. Өтер ни өчен куелган?**

Звонок булгач, дәрес башланды.

а) иярченле кушма җөмлә;
б) тезмә кушма җөмлә;
в) эндәш сүз;
г) кереш сүз. .

**16. Аерымланган хәлләр язуда нәрсә белән аерыла?**

а) аерылмый;
б) нокталы өтер;
в) өтерләр белән;
г) сызыклар белән.

**17. Нинди тыныш билгеләре җитми?**

Рөстәм судан чыккач тирә-юньне күзәтә-күзәтә ашыгыч киенә башлады.

а) ике нокта;
б) өч өтер, нокта;
в) нокта
г) ике өтер.

**18.Нинди тыныш билгеләре җитми?**

Күчәрбай сиңа ни булды

а) өтер, сорау;
б) сызык;
в) нокта;
г) нокталы өтер

**19. Ни өчен өтерләр куелган?**

Минемчә, Гаяз мәсьәләне бик урынлы һәм бик дөрес куя.

а) эндәш сүз;
б) кереш сүз;
в) аныклагыч;
г) аерымланган хәл.

**20. Ия белән хәбәр арасында нинди тыныш билгесе җитми?**

а) өтер;
б) сызык;
в) җәя.

**6 курс 11 семестр**
**Тесты**

1. Татар һәм рус теле нинди типологик төркемгә карыйлар?
   а) икесе дә флектив
   б) икесе дә агглютинатив
   в) татар теле – агглютинатив, рус теле – флектив
   г) татар теле - флектив, рус теле – агглютинатив

2. “Чагыштырма тел белеме” курсының төп максаты
   а) татар теленең үзенчәлекләрен өйрәнү
   б) ике телнең дә охшаш, аермалы һәм уртак якларын өйрәнү
   в) татар теленә генә хас үзенчәлекләрне рус теле белән чагыштыру
   г) рус теленең үзенчәлекләрен татар телендә күрсәтү

3. Тата һәм рус телләрендә ничә сузык аваз бар?
   а) татр телендә -12, рус телендә – 6
   б) рус телендә - 6, татар телендә -9
   в) рус телендә – 5, татар телендә -9
   г) татар телендә – 12, рус телендә – 5

4. Татар һәм рус телләрендә ничә тартык аваз бар?
   а) татар телендә – 28, рус телендә – 37
   б) татар телендә –37, рус телендә 30
   в) татар телендә – 27, рус телендә – 27
   г) татар телендә – 37, рус телендә – 37

5. Ике телдә дә сузык авазларга хас күренешләргә...
   а) рәт, күтәрелеш, иреннәрнең катнашу-катнашмавы карый
   б) күтәрелеш, иреннәрнең катнашу-катнашмавы карый
   в) рәт һәм басым гына карый
   г) күтәрелеш кенә карый

6. Татар теле өчен генә хас үзенчәлек
   а) редукция
   б) сингармонизм
   в) палатальләшү
   г) иренләшү

7. Нәрсә ул флексия?
   а) сүз төрләндергеч аффикс
   б) сүз ясагыч суффикс
   в) сүз нигезе
   г) сүз алды префиксы

8. Рус телдә нинди морфемалар бар?
   а) корень, суффикс, окончание

б) префикс, интерфикс, окончание
в) префикс,  корень, окончание
г) префикс, корень, суффикс, окончание

9. Татр телендә нинди морфемалар бар?
а) тамыр, кушымча
б) префикс, тамыр
в) тамыр, суффикс, кушымча
г) тамыр, аффикс

10. Рус телендә исем сүз төркеменә нинди категорияләр хас?
а) род, число, время
б) лицо, число, падеж, род
в) падеж, род, число
г) төрләнми

11. Умный, трудный, торопливый, сосновый, морской  сүзләре нинди ысул белән ясалган?
а) префиксаль-суффиксаль ысул
б) суффиксаль ысул
в) префиксаль ысул
г) морфологик-синтаксик ысул

12. Җәйге, дымлы, сыйныфташ сүзләре нинди ысул белән ясалган?
а) синтаксик
б) морфологик
в) морфологик-синтаксик
г) фонетик

13. Татар телендә исемнәргә хас категорияләр...
а) килеш, сан, тартым
б) юнәлеш, заман, сан
в) килеш, сан, тартым, хәбәрлек
г) төрләнми торган сүз төркеме

14. Татар теле фигыльләренә генә хас үзенчәлекләрне күрсәтегез
а) заман, зат-сан, юнәлеш
б) юнәлеш, заман
в) дәрәҗә, барлык-юклык
г) төркемчә, юнәлеш

15. Рус теле фигыльләренә генә  хас үзенчәлекләр
а) юнәлеш, заман
б) сан, төркемчә

в) вид, род
г) род, заман

16. Татар телендә фигыльләрнең ничә төрләнеш тибы бар?
а) ике
б) өч
в) дүрт

17. Эшлә, яз, күр, работай, терпи, учись фигыльләре
а) хикәя фигыль – глагол изъявительного наклонения
б) боерык фигыль – глагол повелительного наклонения
в) шарт фигыль - глагол сослагательного наклонения
г) сыйфат фигыль – причастие
18. Рус телендә страдательный залогка татар телендә кайсысы туры килә?
а) төп юнәлеш
б) төшем юнәлеше
в) кайтым юнәлеше
г) уртаклык юнәлеш

18. Тезүле бәйләнеш ике телгә дә хас күренешме?
а) татар теленә генә хас
б) рус теленә генә хас
в) ике телгә дә хас
г) ике телгә дә хас түгел

19. Татар һәм рус телләрендә хәбәрлекле мөнәсәбәт кайсы очракта була?
а) тезүле бәйләнеш булганда
б) ияртүле бәйләнеш булганда

20. Татар һәм рус телләрендә компонентлар арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләренә карап сүзтезмәләр нинди төрләргә бүленә?
а) ирекле һәм фразеологик
б) гади һәм катлаулы
в) тезүле һәм ияртүле

**Перечень вопросов для оценки уровня сформированности компетенции ПК-11на этапе «Знания»**

**Устный опрос**

**1 курс**

1. Татар теленең фонетик системасын өйрәнү өлкәсендә эшләгән галимнәрне, аларның хезмәтләрен әйтегез.

2. Нәрсә ул фонетик транскрипция?
3. Сөйләм органнарының авазлар ясаудагы ролен аңлатыгыз.
4. Нәрсә ул тон, шау?
5. Проклитика, энклитика терминнарын аңлатыгыз.
6. Татар телендә сүз басымының ролен билгеләгез. Рус телендә басым үзенчәлеге белән чагыштырыгыз.
7. Ни өчен авазлар төрле үзгәрешләргә дучар булалар?
8. Сузыклар ассимиляциясен аңлатыгыз.
9. Сингармоник параллельләр төшенчәсен аңлатыгыз.
10. Әдәби әйтелешнең тарихи нигезен аңлатыгыз.
11. Әдәби әйтелешне бозып сөйләүнең сәбәпләрен әйтегез.
12. Рус теленнән кергән сүзләр ничек әйтелә?
13. Алфавиттагы хәрефләрнең татар телендәге фонемаларга туры килүен аңлатыгыз.
14. Татар орфографиясенең принципларын рус теле орфографиясенең принциплары белән чагыштырып карагыз.

## 2 Курс

1. Орфоэпия бүлеге нәрсә өйрәнә?
2. Дөрес сөйләргә нинди факторлар комачаулык итә?
3. Морфемалар чигендә авазлар чиратлашуына мисаллар китерегез?
4. Орфография бүлегенең өйрәнү объекты?
5. Нәрсә ул графика?
6. Татар теленең алфавитында ничә хәреф бар?
7. Хәзерге татар алфавитын яттан сөйләгез?
8. Тел белеменең фразеология бүлеге нәрсә өйрәнә?
9. Фразеологик берәмлекләрнең төп билгеләре һәм татар телендә аларның төрләре нинди?
10. Фразеологик берәмлекләрнең барлыкка килү юллары.
11. Фразеологик берәмлекләрнең матур әдәбиятта һәм публицистикада стилистик кулланылышы турында сөйләгез.
12. Тотрыклы әйтелмәләрнең ирекле сүзтезмәләрдән аермасы нәрсәдә?
13. Структур һәм морфологик составлары ягыннан фразеологик әйтелмәләр нинди төрләргә бүленәләр?
14. Нәрсә ул фразеологик ныгыма?
15. Нәрсә ул фразеологик бердәмлек?
16. Нәрсә ул фразеологик тезмә?
17. Телнең лексикография бүлеге нәрсә өйрәнә?
18. Сүзлекләрнең төрләре.
19. Русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр.
20. Орфографик сүзлеләр.
21. Фразеологик сүзлекләр.
22. Диалектологик сүзлекләр.

## 3 курс

1. Сүзләрне төркемнәргә бүлгәндә, нинди билгеләре нигез итеп алына?
2. Исем сүз төркеменә хас грамматик категорияләрне санагыз?
3. Килеш нәрсәне белдерә?
4. Тартым нәрсәне белдерә?
5. Конверсия ысулы белән исемнәр ясалышы турында сөйләгез7
6. Асыл һәм нисби сыйфатлар арасындагы аерманы ничек аңлыйсыз?
7. Конверсия ысулы белән сыйфатларның ясалышы турында сөйләгез?

8. Конверсия ысулы белән алмашлыклар ясалышы турында сөйләгез?
9. Конверсия ысулы белән фигыльләр ясалышы турында сөйләгез?
10. Конверсия ысулы белән рәвешләр ясалышы турында сөйләгез?
11. Рәвешләрдән конверсия ысулы белән кисәкчәләр ясалышы турында сөйләгез?
12. Алмашлыклардан конверсия ысулы белән ясалган кисәкчәләр турында сөйләгез?
13. Фигыльләрдән конверсия ысулы белән ясалган кисәкчәләр турында сөйләгез?
14. Бәйлекләрдән һәм теркәгечләрдән конверсия ысулы белән ясалган кисәкчәләр турында сөйләгез?
15. Конверсия ысулы белән бәйлекләр ясалышы турында сөйләгез?

**4 курс**

1. Нәрсә ул сүзтезмә?
2. Сүзтезмә татар тел белемендә нинди галимнәр тарафыннан тикшерелә?
3. Сүзтезмә нинди сүзләрдән тора, сүзтезмәдәге сүзләрнең җөмләдә янәшә килүе мәҗбүриме?
4. Сүзтезмә җөмлә эчендә караламы, кемнәр җөмләне сүзтезмә төре дип өйрәнгәннәр?
5. Гади һәм катлаулы сүзтезмәләргә мисаллар китерегез.
6. Фразеологик сүзтезмәләр ирекле сүзтезмәләрдән нәрсә белән аерыла?
7. Тотрыклы һәм ирекле сүзтезмәләргә мисаллар китерегез.
8. Тиңдәш хәбәрле гади җөмлә кушма җөмләдән нәрсә белән аерыла?
9. Сүзтезмәләрне тикшерү тәртибен әйтеп чыгыгыз?
10. Гади җөмләләрне тикшерү урнәге турында сөйләгез?

**5 курс**

1. Татар тел гыйлемендә пунктуация бүлеге нинди галимнәр тарафыннан тикшерелгән һәм нинди хезмәтләрдә яктыртылган?
2. Тыныш билгеләрен төркемләүнең үзенчәлекләре нинди?
3. Тыныш билгеләре җөмләнең мәгънәсен белдерүдә нинди роль үтиләр?
4. Тыныш билгеләренең прагматик функциясе нәрсәдә?
5. Фәнни стильгә нинди билгеләр хас?
6. Рәсми стильгә хас үзенчәлекләрне күрсәтегез?
7. Рәсми стильгә хас жанрларны атагыз? Аермаларын күрсәтегез?
8. Рәсми стильгә хас фонетик, лексик, грамматик билгеләр.
9. Публицистик стильгә хас билгеләр.
10. Публицистик стильгә нинди жанрлар карый?
11. ПС язма һәм сөйләмә формалар.
12. Матур әдәбият стиленә нинди үзенчәлекләр хас?
13. Язучының индивидуаль стиле турында сөйләгез?

**6 курс**

1. Рус һәм татар телендә сыйфат сүз төркеме. Асыл һәм нисби сыйфатлар.
2. Рус телендә тартымлы (притяжательные) сыйфатлар.
3. Рус һәм татар телендә сыйфатларның төрләнеше.
4. Рус һәм татар телендә сыйфатларның кулланылышы.
5. Рус һәм татар телендә сыйфатларда дәрәҗә категориясе.
6. Ике телдә дә сыйфатларның ясалышы.
7. Рус һәм татар телендә сан. Төркемчәләре.
8. Рус һәм татар телендә алмашлык.
9. Ике телдә алмашлыкларның төрләнеше
10. Рус һәм татар телендә исемнәрнең ясалышы.

**Письменная работа для оценки уровня сформированности компетенции ПК-11на этапе «Умения»**

## Письменная работа

## 1 курс 1 семестр

***Бирем 1.*** *Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә фонетик анализ ясагыз.*

…Кояшлы көн яктысыннан килеп кергәч, **аеруча** караңгырак булып **күренгән** озын коридор буйлап Гасыйм Сәләхович үзенең кафедрасына таба атлады. Очраган танышлары белән баш кагып кына исәнләшеп узды. Инде үз бүлмәсенә кереп, капрон эшләпәсен чөйгә элеп, өстәле янына килгәч, ул башта таза, иркен креслосында җәелә биреп, бераз хәл алып, тик кенә утырды. Бер-ике генә минут шулай тугарылып утыруга ул соңгы **вакытларда** гына ничектер гадәтләнеп киткән иде. Күрәсең, бу аның йөрәге белән бәйләнгәнгәдер инде. Аннары гына ул эшкә күчә, уйлый һәм хәрәкәт итә башлый. Һәм тиз арада йөрәк тә, хәлсезлек тә - барысы да онытыла. Бары тик эш кенә кала, ә эш сыналган дәва, яшәтә ул кешене! (Ә.Еникидән)

***Бирем 2.****Текстта сингармонизм күзәтелгән очракларга мисаллар китерегез.Төрен билгеләгез.*

Рәсемдәге төсле матур, әкияттәге төсле серле, җырдагы төсле моңлы елга ул Агыйдел... Аның даны зурлыгы белән түгел, хозурлыгы белән таралган. Җырларда аны, күбесенчә, яшь гомергә ошаталар. Чынлап та, бик урынлы ошату. Бик кыска гына вакыт эчендә дә чиксез күп борылышлар ясый, агымын әледән-әле үзгәртеп тора: бер карыйсың – яшәү көче, тормыш дәрте белән аякларын кая басарга, ташып барган көчен кая куярга белми аптыраган егетләр шикелле, ташларны актарып, уң яклап күтәрелгән текә тауларның каты ярларын кисеп, баштүбән ага. Ул ара да булмый, көчле мәхәббәт кармагына эләгү нәтиҗәсендә төн йокысыннан мәхрүм калып, ай яктысына чыгып утырган яшь кызлар төсле, уйга батып китә; ике як ярларында үскән куаклардан асылып төшкән күләгә эчендә бөтенләй агуын онытып тора. Хәтта читчитләрендә төнбоеклар үсүгә дә каршы килми. Аның мондый урыннарын үрдәк-каз кебек кошлар бик яраталар, ләкин тормышлары өчен куркыныч барлыгын белмиләр алар: күл кебек тыныч, төнбоеклы суга булган мәхәббәтләренә каршы килә алмыйча, йөзеп китәләр дә, чоңгылда яткан усал җен авызына барып кергәннәрен дә сизми калалар. Ә Агыйдел аларны күрмәмешкә салыша, бөтенләй дөньясын оныткан төсле тынып, тик тора... (М.Әмирдән).

## 1 курс 2 семестр

**Бирем 1. Сүзләрнең язылыш һәм әйтелеш кагыйдәләрен әйтегез.**

Күрше районга капчыклар алырга киткән колхоз председателе Шәйхи абзый икенче көнне Яуширмәгә кайтып килә иде.

Көн җилле, ак читле кабарынкы болытлар язгыча бик биектән ашыгып агалар, кояш, бозлар арасында йөзгән каек шикелле, бер югала, бер ялтырап килеп чыга, ә каралган кырлар өстеннән, очсыз-кырыйсыз маллар көтүедәй, болытлар шәүләсе шуып үтә. Кичә-бүген генә килгән кара каргалар юл буенда, җилгә кырын торып , сикерә-сикерә йөриләр яки түбәннән генә очып китәләр...

Моннан бер атна чамасы элек яки ике көн рәттән котырган буран бөтен дөньяны мамыктай йомшак кар белән ап-ак итеп салып куйган иде. Буран артыннан ук кар ашыгып эри башлады, бөтен ерганаклардан кырлар өстен тонык гөрләтеп шарлавыклар йөгерде, уйсу җирләргә зур-зур чуар күлләр җыелды... Инде менә иңе-иңе белән кырлар да ачылып килә.

Кечкенә кашёвка чанага урталайга бөкләп салган капчыклар өеме өстенә аякларын читкә салындырып утырган Шәйхи абзый атын атлатып кына бара. Иртәнге салкын белән кайтып җитәргә чамалап, “Якты күл”дән караңгылы-яктылы чыккан иде ул, ләкин Яуширмә җирләренә килеп җиткәндә юл тәмам бозылып өлгерде. Юлның буеннан-буена вак кына гөрләвекләр узыша-узыша шаулап агалар, ара-тирә кар астыннан

чыккан кара җир өстендә соңгы чаналарның киң табан эзләре ярылып ята, чокыр-чакырлар исә су белән тулган. .. (Ә Еникидән)

## 2 курс 3 семестр

**Бирем 1.** Әдәби әсәрләрдән, матбугат битләреннән конверсия ысулы белән ясалган сүзләргә үрнәкләр китерегез.

**Бирем 2.** Аларның җөмләләрдәге синтаксик вазыйфасын билгеләгез.

**Бирем 3**. Морфологик анализ эшләгез.

## 2 курс 4 семестр

**Бирем 1**. Тексттан мөстәкыйль, ярдәмлек, модаль сүз төркемнәренә мисаллар китерегез.Морфологик-синтаксик анализ ясагыз.

**Текст 1.**

Мирхәйдәр Фәйзи гомеренең иң кызыклы һәм мәгънәле өлеше Орск шәһәрендә узган дисәк, һич тә ялган булмас. Бу шәһәргә ул унбер яшендә, мәдрәсәдә укырга дип килә. Димәк, 1902 елның көзеннән шушы калада яши башлый. Атасы Мостафа карт озакламый Иске шәһәрнең үзәк урамына янәшә булган Тау урамында үз йортын төзергә керешә. (Хәзер ул урам Пугачев исемен йөртә.) Ишле гаиләгә исәпләнгән бу йортның аскы каты кирпечтән, өскесе бүрәнәдән салына. Иркен ишегалдында ат араны, арба сарае, утын келәтләре була. Урамга биш зур тәрәзәсе карап торган ул таш йорт әле дә исән-сау, драматург тууга 80 ел тулган көннәрдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсе үтенеченә нигезләнеп анда истәлек тактасы беркетелде. Ә Мирхәйдәрнең үз эш бүлмәсе дә булган икенче кат исә байтак еллар элек янган һәм кабат торгызылмаган. Мирхәйдәрнең ата-анасы шушы йортка 1907 елда Күкшел утарыннан күчеп килгәннән соң, Фәйзуллиннар шәһәр кешесе булып китәләр. Бу вакытта Орск шәһәре Оренбург губернасының иң зур һәм иң бай өязенең үзәге була.

Егерменче гасыр башында Орскида татарлар шәһәр халкының өчтән берен диярлек тәшкил иткән. Калада биш мәхәллә, биш мәчет була. Ә Урал-суның аргы ягында, Европа өлешендә, хәзерге Яңа шәһәрнең бер читендәрәк мөселман атлы казаклары авылы – Ильяс утары була. Шәһәрнең үзендәге дүрт-биш мәктәп-мәдрәсә дә өяз халкы арасында төшеп калганнардан саналмый.

«Мәдәни җомга» газетасыннан

**Бирем 1**. Тексттан мөстәкыйль, ярдәмлек, модаль сүз төркемнәренә мисаллар китерегез. Морфологик-синтаксик анализ ясагыз

**Текст 2.**

Зәй буендагы ул ялгыз шомырт төбенә палаткабызны корып куеп, бер җәйне бик күңелле ял иткән идек без. Мин кармак салып утырам, улым аланда чикерткәләр куа, зәңгәр-кызыл тубын чөеп уйный, тал-тирәк куаклары арасында сайрашучы кошлар белән нидер сөйләшә, уйный-уйный аргач, шомыртның куе рәхәт күләгәсенә ятып йоклап та ала.

Шул көннәрдән бирле шомырт якын дустыбызга әйләнде һәм без улым белән һәр яз шомыртыбызның хәлен белергә бара торган булдык. Шомырт безне бик куанып каршылый, бөреләрен яңа гына ачып чыккан нәни-нәни яфраклы кул-ботакларын изәп, безне сәламли.

Аннары без шомыртыбыз янына аның шау чәчәккә төренер чакларын чамалап киләбез. Бу вакытта әле чияләр, алмагачлар, миләшләр, язгы җилләргә горур гына баш игәләп, үзләренең чәчәк бөреләрен ачар-ачмас кына утыралар. Бу дөньяда үзләре генә белә торган тантана көннәрен көтәләр алар.

Җәй азакларына таба да без шомыртыбызга кунакка киләбез. Дустыбыз безне, авызны бераз бөрештерсә дә, ифрат тәмле чем-кара җимешләре белән сыйлый.

Быел шомыртыбызның яфрак ярган шатлыгын уртаклашырга, ничектер, бара алмый калдык. Шунлыктан аның мул чәчәкле, хуш исле бәйрәменә вакытында барып җитәргә ашыктык.

Шатлыгын уртаклашырга дип килсәк тә, шомыртның бик моңаеп, боегып утырганын күрдек без. Дустыбызның бәйрәменә соңга калдык микәнни? Әнә бит, инде чәчәк таҗларын коеп сибеп тә бетерә язган ул, иң очтагы ботакларында гына берән-сәрән ак тәлгәшләр күренгәли.

